# Чыңгыз Мусин

# Гомер юлы

## Шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
М78

**Мусин Ч.М.**

Гомер юлы: Шигырьләр/Чыңгыз Мусин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 159 б.

ISBN 5-298-03941-3

Әлеге китапка авторның төрле елларда язылган лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланды.
ISBN 5-298-03941-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Мусин Ч.М., 2006

*Үз туган җиремдә*
*Давылы, җиле дә*
*Җаннарга ягымлы, кадерле.*

### *Туган туфрак*

Никтер моңсу була,
Туган туфрагымнан
Бер көнгә торсам да аерылып.
Гүя бу тормышның
Көннәре кояшсыз,
Төннәре күгендә ае юк.

Үз туган җиремдә
Давылы, җиле дә
Җаннарга ягымлы, кадерле.
Канатлар талганда,
Моңаеп калганда,
Дусларым беләләр хәлемне.

Онтылып, онтылып,
Күңелләрем тулып никадәр!
И туган төбәгем,
Синдәге көннәрем
Нигәдер сизелми үтәләр.

### *Авылым*

Салкыннар да инде килеп җитәр,
Сагыш басар тирә-ягыңны.
Кемнәр белән төннәр үткәрерсең,
Кем каршылар алсу таңыңны?
Язларында тәүге җырлар тынса,
Ямансулый кырлар, болыннар.
Кемнәр сөрер кабат бу җирләрне,
Игеннәрне кемнәр урырлар?
Ә кырларда эшнең кызган чагы,
Сөйрә давай, күпме көчең бар!
Һай, көчлеләр кирәк сүндерергә,
Монда янгын – яна көшелләр.
Таулар итәгендә күксел томан,
Офыккача җәйгән колачын.
Олы юлга кеше тәүге тапкыр
Шушы җирдән башлый юл башын.
Бу җирләрдә акыл, хезмәт, илһам,
Яшәешнең башы шушыдыр.
Кырларында яңа җырлар туса,
Ил хорына барып кушылыр.
Озын юллар урап мин дә кайттым,
Ишек шакыйм: зинһар, кертегез.
Бүгеннән соң мине авылыбызның
Үз кешесе диеп йөртегез.
Хыялларым тәмам күккә ашкан,
Болытларга инде тигәндер.
Туган авылым, сагынып кайттым сине,
Мең мәшәкать белән кинәндер.

### *Гүзәллеккә омтылып*

Урман юлы урау-урау,
Эчләрендә куралык.
Куралыкны айкап йөрим,
Хисләремә уралып.

Нигәдер җирнең сафлыгын
Мин күреп туялмадым.
Әле дә бит яши күңелдә
Иң якты хыялларым.

Үземчә тоям җиһанның
Сафлыгын, хозурлыгын.
Гамәлдә сарыф ителгән
Гомерләр озынлыгын.

Яшьлегем – юл башым минем,
Хыял – юлдашым минем.
Максатсыз, хиссез кичергән
Көнем булмасын минем.

Хисләргә күмеләмен дә
Гөлләргә үреләмен.
Тик үксез үткән яшьлекне
Хәтерлим бүген дә мин.

Хәтердә генә калсын тик,
Давыл узган, җил тынып.
Куралыкны айкап йөрим,
Гүзәллеккә омтылып.

### *Бу туфракта*

Тау артыннан офык ягы алсулана,
Күпереп торган туфрак исе басуларда.
Таң алдыннан ал офыкка каршы барам,
Туып килгән яңа көнне каршыларга.

Җирне назлап йомшак кына җилләр исә,
Җирнең өстен җилләр тарый, гөлләр үсә.
Бал кортлары ширбәт җыя, ширбәт эчә,
Чәчәкләрдән чәчәкләргә күчә-күчә.

Ак болытлар атыла кыйбла тарафына,
Мин дә очам гүя җилләр канатында.
Назлы җилләр – күңелләргә татлы дәва,
Зәңгәр күктән нурлар булып бәхет ява.

Бу туфракта һәркемнең дә хәләл көче,
Ишетелми монда дөнья гөрелтесе.
Һәр тарафта күңелләрдән җуелмаган,
Саф табигый тапланмаган гомер төсе.

Еллар узар, гомер үтәр, көннәр үтәр,
Әле җиргә кемнәр килер, кемнәр китәр?
Без китәрбез мәңгелеккә.
Ошбу мохит
Оныкларга изге көннәр бүләк итәр.

### *Күл буенда йөрим*

Күл буенда йөрим.
Сандугачлы иртә.
Хәтер-тойгыларым
Үткәннәргә илтә.

Күңел бу хисләрдән
Дәва табачакмы?
Хатирәләр айкый
Үсмер балачакны.

Күл буенда йөрим,
Тәүге хисне тоеп.
Башлар инде пеләш,
Үскән сакал, мыек.

Яманнардан яман
Без кичергән заман.
Тәүге хатирәләр
Истән чыкмый һаман.

Заман хәзер башка,
Җиңел кәсеп башта.

Һәммә нәрсә мулдан,
Тик эш килми кулдан.

Бу тормышлар – уен,
Табын тулы сыең.
Кадерен белеп яшә,
Ят гамәлдән тыен.

Һәр көн шулай иртән
Күл буеннан үтәм.
Чуалып ла беткән
Гомер җебен сүтәм.

### *Чиратлар*

Көтү чираты да килеп җитте,
Сәгать угы кебек әйләнеп.
Авыл агаеның һәр минуты
Мал-туарга тора бәйләнеп.

Һәр гамәлнең була үз чираты,
Тик көттереп килә җәйләре.
Җәй ул газап авыл агаена,
Ә кемгәдер – тормыш бәйрәме.

Чиратларга инде күнеккәнбез:
Кибет, фатир, хаста чираты.
Чират көтми җирдән китеп бара
Хатын-кызы, күпме ир-аты.

Чиратларсыз күпләр фатир ала,
Чиратларсыз керә кибеткә.
Ансына да инде күнегелде,
Сүз әйтмисез шуны күреп тә.

Көтү чиратында гаделлек бар,
Бер гаделлек гомер итүдә.
Кеше чиратына кеше керми,
Чират җитми чыкмый көтүгә.

### *Авылым таңнары*

Мең мәшәкать белән дөнья куып,
Җәфа чигеп иртә таңнардан.
Изге гамәл кылган авыл халкын
Кем бар микән илдә аңлаган?

Авыл агаеның игелеген
Кем бәяли аңлы рәвештә?
Күк катыннан торып игенчегә
Дога кылган, диләр, фәрештә.

Күкрәгендә күкрәп иген үскән
Кырларына чыгып кара син.
Болыннарын җәяү урап кайтсаң,

Йөрәгеңә дәва табарсың.

Әтәчләре иртә таңнан торып,
Бар тарафка суза авазын.
Сәрби әби, тәһарәтен алып,
Укый әнә изге намазын.

Әтәчләргә ирек бу дөньяда,
Хатыннары әнә никадәр.
Көнләү дә юк алар арасында,
Тату гына гомер итәләр.

Күп очракта бер бичара ирне
Гел боргычлап торса хатыны.
Монда башка тормыш хөкем сөрә,
Һәр кетәктә әтәч законы.

Бер табигый үзгә мохит монда,
Төннәр үтеп, таңнар җитүгә.
Яшь киленнәр, сыерларын савып,
Малкайларын куа көтүгә.

Бәйгеләрдә чапкан тулпар атның
Ялларыннан килә сөясе.
Төнлә белән ефәк толымнарын
Үреп куйган абзар иясе.

Тын урамга сихри аваз сала
Көтүченең быргы, курае.
Быргычының дәртле моңын тоеп,
Күктә бии сабан тургае.

Туган төбәгемнең хозурлыгын
Яши-яши күбрәк аңладым.
Язмыш мине кая ташласа да,
Юксынырмын авылым таңнарын.

*** * ***

Авыл инде картлык кичерә.
Утын белән якмый миченә.
Тик шулай да авыл тарала,
Буш нигезләр кая карама.

Авыл инде картлык кичерә.
Үткәннәре төшә исенә.
Балалары яши калада,
Хатлар йөри ике арада.

Авыл һаман картлык кичерә,
Яшь чаклары керә төшенә.
Мескен хәлдә калган өстенә
Илгә һаман иген үстерә.

***Татар йорты***

Урыс капка, нарат такта,
Түбәсенә калай япкан.
Хуҗасының кем булуы
Күренеп тора урам яктан.

Капкасы киң, өе биек,
Гүя күккә тора тиеп.
Хуҗа кеше ихатада
Яшәп ята хезмәт сөеп.

Татар йорты, урыс капка,
Өлгеләре бизәк-бизәк.
Эче күркәм, тышы күркәм,
Бар тарафны тора бизәп.

Дөнья иркен, тормыш бөтен,
Морҗасыннан чыга төтен.
Оланнары еракларда,
Ялгыз башка яшәү читен.

Ни диясең балаларга?
Яши алар калаларда.
Тик нигәдер хат-хәбәр дә
Килми якын араларда.

Кала ягы ерак ара,
Бу хәзинә кемгә кала?

### *Гомер узган саен*

Туган яклар күбрәк искә төшә
Гомер узган саен.
Маңгаеңа еллар тирән-тирән
Эзләр сызган саен.

Иркәләсә, назласа да сине
Чит җирләрнең җиле.
Гомер узган инде, үткәннәргә
Кайтып булмый кире.

Чит җирнең дә якты түрләре бар,
Биек үрләре бар.
Тик шулай да хыял үрләренә
Кемнең менгәне бар?

Үткәннәргә кире кайтыр өчен
Юктыр инде чара.
Туган якның кадерен белер өчен,
Читкә китеп кара.

### *Күзләргә керәбез*

Күзләргә керәбез, күзләргә,
Күзләрдә һавалар үзгәрә.

Игеннәр урылган, мул табын,
Яратам авылның шул чагын.

Күзләргә керәбез, күзләргә,
Нигәдер сагыш-моң йөзләрдә.
Һавалар дымланган, куерган,
Кошлар да ышыкка сыенган.

Күзләргә керәбез, күзләргә,
Табигый серлелек үзәндә.
Һәркайда гадәти моңсулык,
Җәйләрдән аерылу сизгәнгә.

### *Соңару*

Авыру ана зарыгып улын көтә,
Еракларга төбәп карашын.
Соңгы тапкыр күреп калыйм диеп
Үзе үстергән газиз баласын.

Бала күңеле, диләр, далада.
Юллар ерак ике арада.
Тәкъдиреңә каршы барып булмый,
Соңгы әмер килде анага.

Карт ананы гүргә иңдерделәр.
Улы кайтты шактый соңарып.
Төсе булып иске мендәр калган,
Күз яшенә манма чыланып.

### *Кызылъярның кызыл яры*

Кызылъярның кызыл ярын
Язгы сулар актара.
Үрләренең түрләрендә
Азмы серләр саклана?
Агымсулар җилгә юлдаш,
Җил хәтере буламы?
Үткәннәрне хәтерлиме
Бүген авыл урамы?
Үткән көннәр зилзиләсен
Кем бар бүген аңлаган?
Авылда бит ул көннәрне
Күргән кеше калмаган.
Үткәнгә бер телсез шаһит –
Иске мәчет-хәрабә.
Ни хикмәттер зилзиләдән
Исән калган манара.
Давыл дулый һәр тарафта,
Һәр тарафтан җил өреп.
Шыксыз давыл ажгыра тик,
Авызын ачкан җен кебек.
Куш манара. Эчтә гүя

Җилләр уйный җен көен.
Җилгә нәрсә? Җен көе ни,
Азаның да бер тиен.
Тирә-юньгә нур индергән
Тәңре йорты тәүгедә.
Еллар узып инде тузган
Бер хәрабә хәлендә.
Тик нигәдер күңелләргә
Ошбу тараф шом сала.
Заманында бу изге йорт
Нур тараткан булса да.
Көн артыннан көннәр узып,
Еллар узган өстәлеп.
Тик шулай да бу хәрабә
Бүген бик зур истәлек.
Һәр дәвернең үзенә хас
Җәйләре бар, көзләре.
Иске мәчет тупсасында
Даут хәзрәт эзләре.
Басып тора иске мәчет
Җил-давыллар чатында.
Сөйли күк илдән сөрелгән
Шаһиәхмәт хакында.
Бу авылда әз булмаган
Игелекле бәндәләр.
Берәүләре иген иккән,
Кемдер булган сәүдәгәр.
Шаһиәхмәт бик күпләргә
Игелек кылган, диләр.
Кырыслыкта дан тотса да,
Кулы мул булган, диләр.
Тырыш кеше хәлле булган,
Ә ялкаулар йоклаган.
Шаһиәхмәт ялкауларны
Юлда тотып тукмаган.
Тырыш кеше кырыс була,
Кырыс булмый нишләсен?
Күңеле изге авыл халкы
Авыр хәлгә төшмәсен.
Кемдер гомерен багышласа
Хак Тәгалә намына.
Изгелекне күралмаган
Хиссез җаннар табыла.
Яхшылыкка яманлыклар
Һәр заманга хас кебек.
Шаһиәхмәт изгелеге
Кемнәргәдер аз кебек.
Кояш чыга, юл ачыла
Һәрбер тинтәк шымчыга.
Әхмәт байның саф күңелен
Шулар сала борчуга.
Конвойлар айкый авылны,
Наганнарын кыстырып.
Һәрбер ялкау, наданнарның
Күңелләрен үстереп.
Әхмәт йорты.
Һәр тарафтан

Җил өреп торган кебек.
Канлы конвой Әхмәт байга
Наганын корган кебек.
Сарсак буе яшел үлән,
Түрләрендә уйсулык.
Бер гаепсез газиз җаннар
Көн үткәрә борчылып.
Гүя кубып давыл килә
Сарсак Умга ягыннан.
Саф күңелле Әхмәт байга
Күпме яла ягылган.
И Тәңрем, ник насыйп иттең
Бу мәхшәрне күрергә?
Гаиләне конвой белән
Озаттылар Себергә.
Тәгәрмәчләр тук-тук килә,
«Кулак» заты бер вагон.
Китүләре бик авыр шул,
Заманалар болгавыр.
Күренеп кала буш далалар,
Ерагая аралар.
Әрнеп торган яраларны
Инде кемнәр дәвалар?
Ач йөрәкләр ачулы,
Буш шул акча янчыгы.
Буш далада ятып калды
Сәхибҗамал карчыгы.
Рәнҗеп үлде, күтәралмый
Газаплану, җирсүне.
Кулмәгенең һәр җөендә
Бет хәшәрәт үрчеде.
Магниткаың сөргенендә
Күпме «кулак» сөрелгән.
Шаһиәхмәт берьялгызы
Качып китте сөргеннән.
Бер гаепсез хурланулар
Рәнҗүле дә, авыр да.
Өтәләнгән бер карачкы
Кайтып төште авылга.
Төнлә белән кайтты Әхмәт,
Урап авыл тирәсен.
Дөньялар тар, шымчылар бар,
Дөнья хәлен белмәссең.
Монда аны кем көтәдер,
Ни көтәдер, кем белә?
Газиз башын төрле уйлар,
Шомланулар өркетә.
Рисвай көненә калырлык
Ни кылды ул, ни хата?
Үз җирендә чит тоела
Үзе корган ихата.
Кызылъярның кызыл яры.
Кызыл балчык катламы.
Изге җирдә Шаһиәхмәт
Сыеныр җир тапмады.
Иске зират, кыргый үлән,
Җил җилгәрә орлыгын.

Ялгызлыктан бәгырь яна,
Җанда кабер тынлыгы.
Дошманыңа күрсәтмәсен
Мондый адәм хурлыгын.
Баш өстендә кар-кар килә
Ач козгыннар төркеме.
Күңелкәен юатырга
Юк янында беркеме.
Иске зират, шомлы хисләр
Телгәлиләр бәгырьне.
Каберлекнең кыйбласында
Әнкәсенең кабере.
Изге кабер өстенә ул
Сузылып ятты йөзтүбән.
Хәле китте, яше кипте
Бертуктаусыз үксүдән.
Өнсез хәлдә үз язмышын
Каргады да каргады.
Шул ятудан инде кабат
Торып китә алмады.
Газиз җанын суырып алды
Ана кабере туфрагы.
Бу язмышка, гүя әрнеп,
Җир-ана да сыкрады.
Байлар белән фәкыйрьләрне
Аралый торган заман.
«Кулак» затларын җирләргә
Ярамый торган заман.
Катгый канун.
Үз өстенә
Кем күтәрер гаепне?
Тик шулай да төнлә белән
Җирләделәр мәетне.
Җирләде авыл картлары
Тик кача-поса гына.
Әнкәсе кабере янына –
Газиз җир кочагына.
Ләкин бу хакта берәү дә
Сүз әйтергә базмады.
Әхмәт байның шушы булды
Язмышыннан язганы.

### *Барҗы Умга якларында*

Иж сулары дулкынлана,
Җанны назлый кыйбла җиле.
Барҗы Умга яклары бу,
Зур әдипнең туган җире.
Барҗы Умга, Барҗы Умга,
Таҗи Гыйззәт туган монда.
Киндер күлмәк, киндер ыштан,
Чабатасы тузган аның.
Яшьлегенең һәр мизгеле
Михнәт белән узган аның.
Офыкларга күзен текәп,

Юл чатында торган басып.
Бәхет эзләп чыгып киткән,
Аркасына биштәр асып.
Ач-ялангач көннәре бар,
Алда тормыш үрләре бар.
Яшь егетнең йөрәгендә
Ачылмаган серләре бар.
Күңелендә – иҗат дәрте,
Күңелендә – изге теләк.
Бу тарлыкка сыямы соң
Халкы өчен янган йөрәк?!
Барып чыга Әгерҗегә,
Китә Ижау каласына.
Тимер кисә, тимер ташый
Таш диварлар арасында.
Җәяү йөри Ижау белән
Барҗы Умга араларын.
Язмыш шулай каһәрли шул
Күпме адәм балаларын.
Өермәле давыл аны
Ташлый Казан якларына.
Каршы ала аны Казан
Чүпле урам чатларында.
Үз кыйбласын таба Таҗи,
Таба Казан каласында.
Иҗат итә, янып яши
Дус ишләре арасында.
Авыр көннәр артта калган,
Башта инде шөһрәт Таҗы.
Авылдагы якташларга
Киңәш хаты юллый Таҗи.
Ни дисәң дә авыл бит ул,
Анда яшәү авыр бит ул.
Авыл хәлен һәркемгә дә
Белеп тору зарур бит ул.
Иген иккән – илгә терәк,
Табын күрке – нигъмәт кирәк.
Яза Таҗи якташларга,
Иминлек һәм уңыш теләп.
Һәр төбәкнең үзенә хас
Җәйләре бар, көзләре бар.
Барҗы Умга якларында
Таҗи Гыйззәт эзләре бар.
Якташларның хәтерендә
Сагыну, сагыш сүзләре бар.

### *Ата йорты*

Син авылда туып үстең,
Көмеш чишмә суын эчтең.
Син туганга сөенгәндер
Атаң мескен, анаң мескен.
Итмәдең син илдә хезмәт,
Чыгып киттең бәхет эзләп.
Торган җирең калададыр,

Моннан ерак арададыр.
Тик шулай да йөрәгеңдә
Сагыну хисе яңарадыр.
Уйлыйсыңдыр җәйләреңдә
Атлар көткән болыннарны.
Иж буеның тугаенда
Яллар иткән урыннарны.
Еллар узган, өең тузган,
Сиплисе бар, корасы бар.
Атаң-анаң юлдаш иткәндә,
Изге гадәт-йоласы бар.
Уйлан әле, ыграк уйлан,
Туган җирдән кемнәр туйган?
Кайтуыңны көтә-көтә,
Атаң-анаң дөнья куйган.
Килер көнең алда кебек,
Куанычың янда кебек.
Кайт илеңә, йөрмә читтә,
Адашкан бер карга кебек.
Кайтыр җиреңизге синең,
Килер көнең – көзге синең.
Кадерен белеп яшәү кирәк,
Ата йорты – ныклы терәк.

### *Дөнья гаме*

Тугайларны урап кайтыйм әле,
Чәчәкләрнең хуш исләрен татып.
Хыялымда яшьлегемә кайтып,
Бер моңланыйм үләннәргә ятып.

Аланнарым буйлап йөрим әле,
Меним әле Тәмәй үрләренә.
Балачакның гүзәл хатирәсе
Әле дә минем күңел түрләрендә.

Иж буенда күптән йөргәнем юк,
Еллар кырыс, еллар ашыктыра.
Хафаланмый гына яшим дисәм,
Дөнья гаме иңгә басып тора.

### *Нигез*

Ниятем акыл сату да
Бушану гына түгел.
Буш урамнарга карыйм да,
Сыкранып кала күңел.

Үсмер буын алдан чаба
Замана тизлегеннән.
Күпме тамырлар йолкынган
Туган як нигезеннән.

Кайда ул кичке уеннар?

Кайда ул хисле күңел?
Табигать тә хәзер никтер
Табигый кебек түгел.

Кайда ул кичке эңгердә
Илаһи гармун моңы?
Сихри моңнарга изрәгән
Кичләрнең талгынлыгы.

Безгә бит күк катларыннан
Ак бәхетләр яумады.
Якты көннәрне төн итте,
Төнне төнгә ялгады.

Балачакта мәхрүм булып,
Ятим калып, ач калып.
Туган якта ни күрсәк тә,
Илне ташлап качмадык.

Туган нигезне калдыр да
Каядыр олак, имеш.
Үз җирендә җир сөргәннәр
Һәммәсе юләр, имеш.

Эзләрең калдыр ызанда,
Ерак бабаңнар кебек.
Кендегең белән берек син
Туган туфракка берүк.

Гел актан гына тормый шул
Дөньяның асыл йөзе.
Кара туфрак – изге нигез,
Ата-баба нигезе.

### *Тәрәзәләр*

Тәрәзәләр карый урамнарга,
Корган нигез кала оланнарга.
И Ходаем, үзең сабырлык бир,
Гомер сөреп, оя корганнарга.
Нигез корган якты хатирәләр
Нигез ташларына уелып кала.
Хыял күгендәге татлы хисләр
Гомер юлларында коелып бара.
Нәсел агачының орлыкларын
Җил-давыллар сибә еракларга.
Сабырлык бир, Тәңрем, туфрагында
Хәләл тормыш корган ир-атларга.
Тәрәзәләр карый урамнарга,
Тирә-якны бизи өлгеләре.
Тәрәз төбендәге сулмас гөлләр –
Игелекле яшәү билгеләре.
Якты тәрәзәдәй якты өмет
Тормыш юлын сафландыра гына.
Туган якта яшәп нигез корсаң,
Гомер юлың булыр актан гына.
Язмышларга каршы юктыр чара,

Серле сукмаклардан еллар чаба.
Изге мирас – корган нигезләрнең
Кадерен белер микән бала-чага?

### *Гөлдем тавы**

Карлар эри, ташу басар,
Гөлдем тавы аллана.
Сизелми дә ага гомер
Бу тынгысыз заманда.

Гөлдем тавы күпне күргән,
Гөлдем ягы – изге урын.
Яшь наратлар, тып-тын калып,
Тыңлый кебек гасыр җырын.

Заманында бу якларга
Ябырылган дошман явы.
Дәверләрнең язмышына
Шаһит булган Гөлдем тавы.

Килер көннәр – кара пәрдә...
Тынамы соң заман шавы?
Манараны кискәндә дә
Сыкрангандыр Гөлдем тавы.

Гөлдем ягы яшел үзән,
Гасыр эзе үрләрендә.
Буыннарның фаҗигасе
Якташларның йөрәгендә.

### *Яшьлек хисе*

Гомерем буе күреп туя алмыйм
Гүзәллеген якын-тирәнең.
Яшьлегемә кире кайткан кебек,
Иж буеннан кайтып киләмен.

Балачакның гүзәл хатирәсе,
Тойгылары яши йөрәктә.
Туган ягым, син бит минем өчен
Ышаныч та, ныклы терәк тә.

Монда минем үксез балачагым,
Монда узды гүзәл яшьлегем.
Әле дә исә йөрәк түрләремдә
Яшьлек хисен тоеп яшимен.

### *Барҗы*

*Мансур Вәли-Барҗылыга*

Авылсыз калырбыз диеп
Кем бар иде уйлаган?
Көтмәгәндә гүзәл Барҗы

Юк ителде дөньядан.

«Язылмаган кануннар» бар,
Бар җанга кагылганы.
Изге җирне изеп үтте
Замана агымнары.

Бәлагә тарыган авыл,
Янгынсыз янган авыл.
Тын һавада җил-давылсыз
Таркалып калган авыл.

Бу тараф – изге затларның
Эзләре калган җире,
Гасырлар буе күпләрнең
Тирләре тамган җире;

Һәркемнең дә тәүге тапкыр
Тәпи атлаган җире,
Балачак хатирәләрен
Җанда саклаган җире;

Күңелдә исеме калса да,
Асылын җуйган урын,
Күпләрнең кайгы-сагышын
Үзенә җыйган урын.

Авылсыз калган әдипләр,
Тамырсыз калган авыл.
Авыр бит хисле җаннарга,
Авылсыз яшәү авыр.

## ***Йөрәк ярасы***

*Фаҗигале төстә яшьли арабыздан киткән дустым Альберт Сәхбетдиновның якты истәлегенә*

Аның чәче кара бөдрә иде,
Чал түгелләр иде берсе дә.
Ихлас күңел белән якын күргән
Бер дустым бар иде күршедә.

Балалары үсеп килә иде,
Тормышы да булды түгәрәк.
Иж буеның сөзәк үрләрендә
Утын кисә идек бергәләп.

Искә төшсә, әле дә каннар саркый
Йөрәктәге тәүге ярадан.
Рәхимсезлек нигә чүпли микән
Яшь җаннарны безнең арадан?

## ***Уртак дуслык***

Сарсак Умга, Барҗы Пельга –

Күрше удмурт авыллары.
Кем керсә дә, сый-нигъмәттән
Тулып тора табыннары.

Җил-давыллы заманнарда
Абынганбыз, сөрлеккәнбез.
Инде элек-электән без
Бер туфракка береккәнбез.

Кемдер корган сәясәттән
Әрни генә уртак яра.
Айлар, еллар узган саен
Якыная безнең ара.

Күңелләрдәге сагышны
Иделләргә саласың да,
Самимилек хисе арта
Удмурт, татар арасында.

### ***Каз өмәсе***

Каз канаты кат-кат була,
Мамыклары ап-ак була.
Өмәләргә бара кызлар,
Вак-вак итеп атлап кына.

Аяз иде әле кичтән,
Таңда җиргә ак кар төшкән.
Бездә бүген каз өмәсе,
Уен-көлке безгә күчкән.

Гөрләп уза каз өмәсе,
Өмәле йорт сыйлы була.
Яшь кызларның йөрәгендә
Онытылмаслык тойгы була.

Өмәләргә йөрми генә
Сүнеп тордык бер араны.
Әллә ничек санламадык
Изге гадәт-йолаларны.

Су буена бара кызлар,
Каз каурые сибә-сибә.
Өйләрдәге җыр-биюләр
Кучә бәке тирәсенә.

Һәр ел шулай гөрләп узсын
Авылларда каз өмәсе.
Бу йола бит милләтемнең
Изге рухи хәзинәсе.

### ***Җиде юл чатында торасың***

Җиде юл чатында торасың,
Машина көтәсең китәргә.
Нигезең бу якта булса да,

Тормышың еракта, читләрдә.

Аякта – үкчәле башмаклар,
Өстең дә шәһәрчә, җиңелчә.
Без кигән олтанлы итекләр
Кимчелек санала синеңчә.

Йортыңа күз ташлап аласың,
Күңелгә борчулар саласың.
Гомергә әйләнеп кайтмам дип,
Рәнҗүле шикелле карашың.

Сездәге тормышлар үзгәдер,
Тормышның «җәннәте» сездәдер.
Әмма син ешрак кайт авылга,
Дөньяга карашың үзгәрер.

Бер китеп кайтулар ярый ла,
Тормыштан гыйбрәтләр алырга.
Тамырың, туфрагың авылда –
Нигә дип читләрдә калырга?

### *Сусыз тегермән монологы*

Элек мине авыл агайлары
Елга суын буып корганнар.
Әйләнәмне урап алган иде
Киң болыннар, яшел урамнар.

Инде ятим ул елга ярлары,
Усал язмыш нигә алдады?
Күчерде дә колхоз утарына,
Өч чыбыкка мине ялгады.

Заманында су иркендә идем,
Сулар ага иде арыктан.
Заман мине нигә каһәрләде?
Язмышыма нигә каныккан?

Хәл-әхвәлләр шушы чамада шул,
Тәүге хисләр кабат яңара.
Тегермәннәр куласасы кебек
Әйләнә дә тора замана.

Мин чыгарган оннан авыл халкы
Ипи сала иде әвәләп.
Үзләре дә һәрчак тук булдылар,
Балалары үсте тәгәрәп.

Их бу ярлар, их бу текә ярлар
Ташкыннарга ничек чыдаган?!
Элгәре мин он чыгара идем,
Хәзер инде көрпә чыгарам.

Рәхимсезлек минем язмышымны
Өч чыбыкка нигә бәйләгән?
Заманында су иркендә идем,
Коры җирдә хәзер әйләнәм.

***Татар дөньясына мулла кирәк***

Татар авылына мулла кирәк.
(Заманалар бетте болганып.)
Догаларсыз гомер иткәнгәме,
Ят тоела әле муллалык.

Капка төпләренә җыйналышып,
Өлкәннәрне күпме барладык.
Рухыбызны кабат яңартырдай
Кулай бәндә таба алмадык.

Без яшәгән кыргый заманада
Муллалыкка кемнәр укыган?
Тәүге тапкыр гүя күзне ачып
Уянабыз кебек йокыдан.

Бу дөньяда инде ни кылсак та,
Белмәгәнбез гөнаһ, оятын.
Әй замана! Ахры, татарны син
Йокысыннан соңрак уяттың.

Иңке-миңке яшәп яткан мәлдә
Ерак киткән инде кәрваннар.
Кешеләр бит әнә өнсез хәлдә,
Гөнаһларга күмелеп калганнар.

Туган җирем, изге җирем минем,
Кем иркенә калды мәхәлләң?
Урамыңнан җәяү узар хәл юк,
Шайтан ергалаган җәһәннәм.

Кырларыңа чыксам әүвәлгедәй,
Иркәләми инде яз моңы.
Тургайларың сине ташлап киткән,
Инешләрең – чучка сазлыгы.

Ә күгеңдә якты кояш йөзә,
Эңгер төшә, йолдыз атыла.
Кеше башын ашый кайберәүләр
Бер типтереп яшәү хакына.

Ә җиһанның гүя бер гаме юк,
Әйләнә дә һаман әйләнә.
Дөнья белән бергә әйләнәләр
Күпме мәкер, күпме хәйләләр.

Яшьлек язы килсә канатланып,
Яз бөресе җирдә ярала.
Тик озакламый сары көзләр җитә,
Бер күз ачып йомган арада.

Тормышта без нинди эз калдырдык?
Үткәннәргә бераз күз салыйк,
Кешегә бит гомер ике килми,
Һай, гомерләр бигрәк кыска бит.

Татар авылына мулла кирәк,

Бик кичегеп кенә булса да.
Кыйблабызга карап юлга чыктык,
Изге юллар булыр, иншалла!

### *Кырындыда бер көн*

Яшәсәк тә төрле төбәкләрдә,
Уртак икән әле рухыбыз.
Менә бүген монда, Кырындыда,
Илһамланып шигырь укыйбыз.

Юлыбызга чыгып каршы алды
Ярым айлы изге манара.
Әйтерсең лә, догалыгын тотып,
Үз асылына кайткан замана.

Дөньялары бозык, тик шулай да
Иманлы җан таба кыйбласын.
Дулкынлана йөрәк, и Ходаем,
Изгеләргә бәхет юлласын.

Манарага кунган ярым айның
Мәңгелеккә булсын балкышы.
Рухыбызны кабат кимсетмәсен
Мәгънәсез бер заман тартышы.
Кырындыда бүген шигъри бәйрәм,
Сөйләп кенә сүзләр бетәрме?
Очрашкалап күңел юатсак та,
Сафларыбыз сирәк бит әле.

Безнең якта «җирләр уңдырышлы»,
Чәчик әле рухи орлыклар.
Шул орлыклар җирдә шытып чыксын,
Уңышларын җыйсын оныклар.

### *Туган көнем*

Узган гомерләрне уйлыймын да,
Уйларымның очы югала.
Менә быел минем туган көнем
Туры килде изге җомгага.

Мин туды дип гомерем сукмагына
Беркем затлы келәм җәймәгән.
Тәңрем мине юктан бар иткән дә
Язмышымны җиргә бәйләгән.

Шатлык иңгән йортка, мәҗлес җыеп,
Исем куштырганнар мулладан.
Дога кылган миңа изге хәзрәт,
Юлларыма бәхет юраган.

Туган көн дип шау-шу ясамыйм ла,
Мәҗлесләрдә урыс уласын.
Гадичәрәк кенә уздырырмын
Милләтемнең изге йоласын.

Мин тормышта хата кылган булсам,
Әрләмәгез бүген сез мине.
Бу бит минем гомер сәгатенең
Алтмыш тапкыр суккан мизгеле.

Авыл халкы бит ул шатлыкны да,
Кайгыны да бергә күтәрә.
Миңа бәйрәм, ләкин бер изге җан
Дөнья куйган шушы иртәдә.

Таң беленеп якты көн тууга,
Бер төбәктә күпме бимаза.
Бер үк көнгә туры килер икән
Кемгә – бәйрәм, кемгә – җеназа.

Иртә таңда берәү вафат булган,
Моңсу булып калды күңелгә.
Изге теләкләрем кабул булсын,
Урыны булсын оҗмах түрендә.

Кемдер туа, кемдер дөнья куя,
Ятим кала корган оялар.
Кайберәүләр хәтта үз иркеннән
Гомеренә нокта куялар.

Ни булса да булыр, минем әле
Киң җиһанда бурычым бетмәгән.
Тәңрем мине юктан бар иткән дә
Тау кадәрле эшләр йөкләгән.

Ни сәбәптер, ошбу дөньяга син
Көлеп түгел, елап туасың,
Буй җиткереп кеше буласың да,
Гомер буе дөнья куасың.

Бала чактан күпме таптап уздым
Тәмәй тауларының итәген.
Үргә менгән саен күбрәк белдем
Бу дөньяның серле икәнен.

Урал тауларының, һай, кыясы,
Кыясында – бөркет оясы.
Чит җирләргә китсәң, якын икән
Туган якның назлы кояшы.

Чит җирләргә күпме табынсаң да,
Саф булса да аның һавасы.
Һәр кешенең килә соңгы чиктә
Туфрагына кайтып авасы.

Ә мин инде тормыш юлларында
Күпме ялган-яла күтәрдем.
Телгәләнеп беткән йөрәк белән,
Белмим, күпме гомер итәрмен.

Их син, дөнья, их син, серле дөнья,
Корылгансың ялган, мәкергә.
Куанычлар никтер истән чыккан,
Кимсенүләр әле дә хәтердә.

Кемдер туа, кемдер дөнья куя,
Сизелми дә уза гомерләр.
Без кичергән еллар иңсәсендә
Кала фәкать көлле күмерләр.

Зилзиләле еллар агышыннан
Үз куышың тетри, үз түбәң.
Без генәме, мәкер тозагыннан
Падишаһлар төшә йөзтүбән.

Бу җомгада минем туган көнем,
Алсу шәфкать иңде таң булып.
Киң җиһанның газиз бер көнендә
Мин китәрмен сезне калдырып.

Мин үлгәч тә алсу таңнар атар,
Ел артыннан еллар үтәрләр.
Оныкларым минем мин калдырган
Эшләремне дәвам итәрләр.

### ***Гүзәллек дәрьясы***

Таң туа, җир өстенә рәшә төшә.
Агыла моң, чәчәкләргә күчә-күчә.
Күңелемне тибрәндерә шушы агым,
Илаһи гүзәл минем туган ягым.
Офыклар балкый гаҗәеп төс белән,
Һәр бөҗәк үзенчә мәшгуль эш белән.
Ерактан, урман-кырлар, таулар кичеп,
Иртәнге назлы җилләр килде исеп.
Бу чәчәкләрдә күпме буяу төсе,
Бөркелә тирә-якка хушбуй исе.
Тургайлары менгән зәңгәр күгенә,
Җир өстенә сихри моңнар түгелә.
Таңнарда хәтфә болыннарга чыгып,
Ялгызым йөрим шулай уйга чумып.
Иртәләрдә серлемен дә моңлымын,
Бозармын дип ошбу дөнья тынлыгын.
Йөримен саф хисләрем ташып-ташып,
Үләнгә йомшак-йомшак кына басып.
Күңелләргә мәңгелек илһам ява,
Туң йөрәкләрне эретерлек дәва.
Бу хакыйкать – яшәешнең асылы,
Саф гүзәллек дәрьясының ташуы.

### ***Шагыйрьләр килгән авылга***

Шагыйрьләр килгән авылга,
Авылда бәйрәм киче.

Һәммәсен тарткан мәйданга
Шигырьнең сихри көче.
Туган җирләр, изге җирләр
Шигырьгә, җырга гашыйк.
Игенче күмә бөртекне
Җыр белән бергә кушып,
Шагыйрьләр шигырь укыйлар,
Тулган ай йөзә көлеп.
Бу тылсымнан бөтен авыл
Тирбәлеп тора кебек.

## ***Яңа ел***

Килеп җитте декабрьнең соңгы көне,
Кар астында инде кырлар, басулар да.
Еракларданн, еракларданн кайта кеше,
Яңа елны туган якта каршыларга.
Үз ягына мәхәббәте суынмаса,
Һәркемне дә туган туфрак, нигез тарта.
Яңа елны туган йортта каршыласаң,
Бу дөньяда бер гомерлек дәртең арта.
Илаһи бер хозурлыкта уза минем
Хыялымда гәүдәләнгән татлы гомерем.
Шул гомеремнең бер мизгеле Яңа елда,
Дусларыма бәхет тели керсез күңелем.

## ***Кунаклар кайта каладан***

Кунаклар кайта каладан,
Кайталар атна саен.
Купшыланып, көязләнеп
Кайталар кайткан саен.

Суык чакта җылы эзләп
Китәннәр кайта урап.
Һич исәбе юк кунакның,
Өй саен тулы кунак.

Туган туфрагын сагынып,
Талпынып кайта кеше.
Кояшның тарту көче күк
Авылның тарту көче.

И гүзәл туган ягымның
Кичләре, иртәләре,
Ягымлы, назлы җилләрнең
Битләрдән иркәләве.

Уйнап йөри йомшак җилләр,
Һавалар җылы тора.
Уяна дәртле тойгылар,
Кайгылар онытыла.

Тоя микән бу ләззәтне
Каладан кайткан кунак.
Күңелкәен юатмыймы,
Бары хәл-әхвәл сорап.

Онытылмыйдыр туган якның
Йолдызлы, айлы киче.
Алдагы көнен уйламый,
Үткәнен уйлый кеше.

Кунаклар кайта каладан,
Җәйләрен дә, кышын да.
Кайтсыннар иде китмәскә,
Калырга дип шушында.

## *Агымсуда акчарлаклар*

*Шагыйрь Ринат Батталовка*

Агымсуда йөзә акчарлаклар,
Ага сулар ярны актарып.
Иҗат дәрьясында колач җәеп,
Шигырь яза Ринат Батталов.

Шигырь яза Ринат. Җитмеш төрле
Гамәл дә аз, диләр, ир-атка.
Бер карасаң, ул бит эш аты да,
Шул ук чакта шагыйрь Ринат та.

Зилзиләләр кубып актарылган,
Нигездән ул күптән аерылган.
Хакыйкатьтән аймыл булмаган ул,
Тик канаты гына каерылган.

Әрнү катыш булган тәүге хисме
Шагыйрьлеккә аны этәргән?
Кубарылган нигез тамырлары,
Кем бу хисне җиңел күтәргән?

Их... авылсыз шагыйрь, иҗатыңда
Чагыла синең йөрәк хисләрең.
Сагынып кайтасыңдыр буш нигезгә
Туган якның айлы кичләрен.

Күңелләрдән җуеп булмыйдыр ул
Гүзәллеген туган якларның.
Юасыңдыр гүя, шигырь язып,
Җир йөзенең кара тапларын.

## *Моң тулы йөрәгем*

*(Җыр)*

Моң тулып киләдер,
Җыр туып киләдер
Җыр сорап йөдәткән күңелгә.
Сагыштан бушаган,
Моңнарга сусаган,
Хис тулы йөрәкнең түрендә.

Ярсыды йөрәгем,
Син булдың терәгем
Әрнүле, сагышлы көннәрдә.
Хисләрем яңарды,
Сагышлар таралды,
Тик сиңа табынып йөргәндә.

Иң тәүге елларда,
Без йөргән юлларда
Үләннәр каплаган эзләрне.
Хыяллар киң иде,
Җырларга тиң иде,
Нигәдер язмышлар үзгәрде.

### *Йөрәк ялкыны*

Күп еллар янәшә атладык,
Тормышның серләрен ятладык.
Ялкынлы мәхәббәт хисләрен
Күңелдә һәрвакыт сакладык.

Чәчәкләр бирмәдем бүләккә,
Мәхәббәт ачкычы йөрәктә.
Йөрәкләр йөрәккә бәйләнде,
Сүрелмәс ялкынга әйләнде.

Булмады тормышның назлары,
Шул булды язмышка язганы.
Килсә дә кышларның салкыны,
Җылытты йөрәкләр ялкыны.

Яшәгән гомерләр төш кебек,
Без тәүге кавышкан кич кебек.
Дөньялар тордылар үзгәреп,
Тик үткән гомерне сизмәдек.

### *Бәхет юллары*

Саф мәхәббәт дәва, диләр,
Йөрәк яраларына.
Шуңадыр изге хисләрем
Һаман яңара гына.

Көзләр килде, сары көзләр,
Юлыбыз урау гына.
Сары төс – сагыш, диюләр
Гадәти юрау гына.

Борма-борма озын юллар,

Ничек табыйк уңаен?
Бу серле тормыш юлында
Адаштырма, Ходаем.

Сикәлтәле тормыш юлы,
Сөрелгән ызан кебек.
Болганды еллар, тузгыды,
Юлдагы тузан кебек.

Искермәде хисләребез,
Дөнья болганды гына.
Урау булса да юлыбыз,
Бәхет юллары гына.

### ***Сиңа***

Хәтердә язгы кичләрдә
Беренче танышулар.
Һәркемнең гомер юлында
Онытылмас табышы бар.

Елмаеп, иләс күңелемне
Нурыңа манган идең.
Мин, тиле, синең алдыңда
Югалып калган идем.

Йөрсәң дә яшьлек язында
Читләшеп, ялындырып.
Сизмәдең дә калганыңны
Гомерлек ярым булып.

Бу гүя татлы гомернең
Беренче киче генә.
Җитәкләшеп киләбез күк,
Җәннәтнең ишегенә.

Аерылыр көннәр җитәр
Мәйсәрәгә,
Кем уйлаган бу гомернең
Сизелми дә үтәсен.
Бу дөньядан минме алдан,
Синме алдан китәрсең?

Гомер үтте, узалмадык
Хәзинә сараена.
Үзең хәзинә булдың син
Мин – урам малаена.

Төш кенәдер бергә үткән
Бәхетле мизгелләрем.
Үпкәләгән чагыңны да
Үземә сиздермәдең.

Яшәгән саен инандым
Күңелең аклыгына.
Күпме куаныч китердең
Мин малай актыгына.

Килер рәхимсез минутлар,

Аерылыр көннәр җитәр.
Синме мине, минме сине
Юксынып гомер итәр?

Җитәкләшеп китүләр юк,
Инде ни хәл итәрсең?
Мәхәббәткә безнең кебек
Кем табыныр микән соң?

### *Яшьлек*

Их бу яшьлек, гүзәл яшьлек,
Гомернең күркәм чагы.
Йөрәктәге ялкын булып
Дөрләп янган учагы.

Күңелләрне җилкендереп,
Хисләр ага ургылып.
Аяз күктән җиргә иңгән
Илаһи бер нур булып.

Күңелнең бетмәс-төкәнмәс
Хисләр кабынган чагы.
Гомергә юлдаш булырдай
Дуслар табылган чагы.

### *Сөю-сәгадәт*

Тормышта күпне югалттым,
Аз булды никтер.
Алты дистә елны ваклап,
Җитмешкә китеп барыш.

Юлымда булды абынган
Һәм тайпылган чакларым.
Аякка торып бастым да
Туры юлдан атладым.

Яшәгән саен инандым:
Бу дөнья серле икән.
Тик мәхәббәт уты җанда
Сүнми-сүрелми икән.

Аккан суларга тиңлимен
Гомерләр агышларын.
Җырларымның никадәрен
Сөюгә багышладым.

Сөюдән аладыр һәркем
Илаһи яшәү көчен.
Туадыр кеше бу җиргә
Сөелеп яшәр өчен.

Тик мәхәббәттән торадыр

Дөньяның асыл төсе.
Бәхетле булалмыйдыр ул
Сөю белмәгән кеше.

### *Улымны өйләндерәм*

Күп яшәдем.
Бу гомернең
Ләззәтен, тәмен беләм.
Кешеләр бит парлы-парлы,
Улымны өйләндерәм.

Улымны өйләндерәм дә
Бәхеткә кинәндерәм.
Бу дөньяда берәү дә бит
Яшәми берәм-берәм.

Чын күңелемнән өйрәтермен
Тормышның вак-төяген.
Бергә-бергә укысыннар
Яшәеш һәфтияген.

Баштан узды замананың
Тәүгесе, яңарышы.
Гасырларга тоташкан бит
Буыннар ялганышы.

Һәркемдә үзгә табигать,
Һәркемдә үзгә холык.
Яшәсәң яши аласың
Бары бер сүздә булып.

Кошлар да бит оя сайлый,
Парлашып сайрар өчен.
Кешеләр яши дөньяда,
Үз тиңен сайлар өчен.

Гаиләбез дә ишәер,
Йортыбыз иркен әле.
Пенсиябез дә җитәрлек,
Яшәргә мөмкин әле.

Заманында зур тормышка
Кемнәр аяк басмаган?
Өйләндерәм малаемны,
Бетте-китте, вәссәлам.

### *Бәхетле мизгелләр*

Синнән яшерен серләрем юк,
Син бит минем фикердәш.
Тугарылам да китәмен,
Сер йомгагым сүтелгәч.

Әйтерсең лә без икебез
Ике игез сыңары.
Шуңа, ахры, икебезне

Бер үк язмыш сынады.

Син – минем гомер юлдашым,
Тик шәхси милкем түгел.
Хисләремне чикләвемнең
Булуы мөмкин түгел.

Кемнең ничек, безнең гомер
Тугры эздәдер кебек.
Бәхетле, якты мизгелләр
Тик ул бездәдер кебек.

### *Йөгән*

Кем дә көчләп түгел, җаның теләп
Бер чибәрне үзең сайладың.
Йөгәнләрмен диеп, йодрык төйнәп
Газапладың соңгы айларын.

Тик ул сылу синдә күп тормады,
Ялтыратты табан дигәнне.
Ә шул көннән башлап инде менә
Карт әниең киде йөгәнне.

### *Ялгышлар*

Туган-үскән нигезеңне
Ташлап киттең, олан.
Урыс арасында яшә,
Урыс булып кылан.

Сагынасыңдыр, кем сагынмас
Туган-үскән җирен?
Ата-анаңны көендер,
Алып марҗа килен.

Сине үстергән гаиләгә
Мең-мең хәсрәт яса.
Урыс арасында төплән,
Урыс булып яшә.

Бу дөньяда ялгышлар күп,
Кем санаган чутын?
Урыс чиркәвенә йөреп,
Урыс булып чукын.

### *Кодагыйлар*

«Минем кызга тиңнәр юк», – дип
Мактый ана кызын.
«Дөньясында бер генә», – дип
Тәмам итә сүзен.

«Бигрәк тәүфыйк иясе», – дип,
Улын мактый берсе...
«Бу дөньяда аңа тиңләр
Кызлар юктыр төсле».

Берсе – улын, берсе кызын
Күккә чөя бирсен.
Бу ике яшь күптән инде
Сөя берсе-берсен.

Бер-береңне өзелеп сөйгәч,
Инде нәрсә кирәк?
Өйләнешеп туй ясыйлар
Бу ике яшь йөрәк.

Кодагыйлар чәй эчәләр,
Яшерен генә көеп.
«Бу затларга тормыш бәйләп
Әрәм булдык», – диеп.

## *Ишкәкче карт*

Ярсый-ярсый сулар ага,
Комлы ярга дулкын кага.
Елга-суның аргы яры
Күз күреме булган ара.
Шадра дулкын уртасыннан
Ишкәкче карт йөзеп бара.
Әй, ишкәкче, килче бире,
Аргы якка илтче мине.
Сөйгән ярым көтә анда,
Минем дәрья кичүемне.
Шадра сулар, көмеш дулкын,
Ярлар биек, кызыл катлам.
Сөзәк үрнең итәгенә
Күксел томан сузылып яткан.
Нурлар иңгән җәйге иртә,
Агымсулар миңа киртә.
Ишкәкче карт, килче тизрәк!
Анда сагынып ярым көтә.

* * *

Синең белән бергә
Керсәк иде гүргә.
Җитәкләшеп кенә, парлашып.
Урыныбыз уңай,
Ятсак иде шулай
Бер-беребезнең хәлен аңлашып.

Яшьлек иртәсендә,
Вәгъдәләшкән кебек,
Аерылмаска диеп сүз биреп.
Кара кабердә дә
Ятсак иде бергә,
Тәүге мәхәббәтне сиздереп.

Салкын каберебездә
Җылы булыр безгә,
Өстә инде тормыш арбабыз.
Ләкин исәннәрнең,
Иске төшкәннәрнең
Хәлен генә белә алмабыз.

### ***Адаштым***

Очраштык та урман сукмагында,
Өнсез калып тордык бер мәлгә.
Үсмер генә бер кыз идең әле,
Мин ул чакта сине күргәндә.

Урман ешлыгына кереп киттең,
Ташлап миңа серле карашың.
Ә мин тиле, сине эзли-эзли,
Шул ешлыкка кереп адаштым.

Шул көннән соң сине гомерем буе
Күңелемнән җуя алмадым.
Күз карашың белән сихерләдең,
Күз карашың белән алдадың.

Урманнарга кереп югалдың да
Күз алдымнан китми карашың.
Мин урманда түгел, тормышта да
Гомерем буе яшим адашып.

### ***Чишмәгә төшкәннәр киленнәр***

*(Җыр)*

Чишмәгә төшкәннәр киленнәр,
Елмаеп балкыйлар иреннәр.
Бу гүзәл мизгелгә сокланып,
Җилләрдә тирбәлә сиреньнәр.

Чишмәгә төшкәннәр киленнәр,
Илаһи гүзәллек, купшылык.
Ишетелә шатлыклы авазлар,
Чишмәләр җырына кушылып.

Чишмәнең тылсымлы як-ягы,
Төбендә чуерташ катламы.
Чишмәгә төшкәннәр киленнәр,
Дөньяның илаһи затлары.

### ***Икеләнү***

Канатланып гомер итәмен дә
Килер көннән нидер көтәмен.
Белсәм дә тик җанда буш өметләр,

Буш хыяллар гына икәнен.

Килер көндә нинди язмыш көтә?
Омтыламын кебек изгегә.
Җанда туган ике каршылыкны
Аңлап булмый ләкин тиз генә.

### *Картаямыни соң йөрәк?*

Яшем алтмыштан узган да,
Гомерем үткән кебек.
Тик күңел никтер ризасыз,
Нәрсәдер көткән кебек.

Таш-таулар кичәр идем дә,
Дусларым риза түгел.
Әйтерсең лә үз-үземә
Мин үзем хуҗа түгел.

Күңелемнең уфтанырлык,
Борчылыр чарасы юк.
Өзелеп сөйгән ярымның
Ятларга каласы юк.

Тапкан малым, капкан наным
Булмады минем язык.
Гомеремне үткәрәмен,
Шигырьләр, җырлар язып.

Алтмыш яшь – тормыш ләззәтен
Татып яшәр чак икән.
«Картаямыни соң йөрәк?»
Дигән сүзләр хак икән.

### *Гомер юлы*

И Ходаем, мәрхәмәт кыл
Балаларга.
Җитмеш яшем тулды шушы
Араларда.
Сизелмичә җиде дистә
Узган гомер.
Бер уйласаң әз дә түгел,
Күп тә түгел.
Җитмеш елым – эш-гамәлләр
Кылган ара.
Гомер арбам келтер-келтер
Әле дә бара.
«Җитмеш яшем, җилле чагым», –
Димен әле.
Җил-җил атлап болыннарда
Йөрим әле.
Ошбу җирдә кеше мәңге

Кунак түгел.
Инде хәзер сиксәне дә
Ерак түгел.
«Гомер уза, еллар бик тиз
Чаба», – димен.
Сиксән яшьнең ни икәнен
Чамалыймын.
Абзарында эш атың юк,
Арбаң ватык.
Үткәннәрне сагынырга
Калган вакыт.
Арт саныңны көчкә-көчкә
Сөйрәр чагың.
Гомер юлын оныкларга
Сөйләр чагың.
Сиксән яшь – ул гомер көзең
Узган чагың.
Оланнарга ике кулың
Сузган чагың.
Язмыш сиңа ни язса да,
Түзәр чагың.
Дус-ишләрнең яннарыңнан
Бизәр чагың.

### ***Җилләр исә***

Көннәр үзгәреп тора,
Җилләр кузгалып тора.
Ахры, тиздән явым булыр,
Билләр сызланып тора.

Җилләр исә, җил җитез,
Җил тизлеге нинди тиз.
Зур казалар салып китә,
Әйтеп булмый берни сүз.

Җил җилгәрә гөлләрне
Болыннарда, кырларда.
Безне дә бит җилгәрделәр,
Илдә давыл булганда.

Ак томанда кар төсе,
Илдә заман тартышы.
Болганулар юкка түгел,
Давыл булыр, ахрысы.

Гүя сусыз дәрьямын,
Сызлана авыру җаным.
Мин генәме?! Дөнья авыру,
Саулыгы юк дөньяның.

### ***Карт юкәләр яшь чәчәктә***

Карт юкәләр яшь чәчәктә,
Карт юкә яшьләр кебек.

Гөл чәчәкләргә күмелеп,
Мәңгегә яшәр кебек.

Юк, көнләмим мин юкәне,
Яшәрсен генә берүк.
Үземдә дә бар югыйсә
Яшәрү дигән өмет.

Бар минем хисле күңелем,
Мин аны җанда тоям.
Карт юкә кеби, җиһаннан
Җәүһәри нурлар җыям.

Мин гүя бер карт юкәмен,
Яшь чәчәк аткан юкә.
Яшьлек эзләремә кайтам,
Зур юллар үтә-үтә.

Күңелем минем яшьлеккә
Битараф күңелмени?
Мәхәббәтне юлдаш итү
Яшәрү түгелмени?

### *Еллар чаба*

Еллар, еллар, кая чабасыз сез?
Тизлегегез бигрәк чамасыз.
Үткән гомерләрне уйлыймын да
Ирексездән калам чарасыз.

Яшьтәшләр дә инде сирәгәйде.
«Кемгә күпме гомер бирелгән?»
Бергә-бергә узган балачакның
Хатирәсе чыкмый күңелдән.

Күләгәдә бер ял итәр идем,
Яшьлек иманемә сөялеп.
Еллар чаба диеп мин дә чабам,
Заман агымына ияреп.

### *Эзләр*

Чебешләрне санар көннәр житте,
Һәр гамәлнең була үз мәле.
Чиратында җәйләр килгән кебек,
Җәй артыннан килә көзләре.

Табигатьнең җирдә үз кануны,
Күпме нәрсә атлый бер эздән.
Тик кешеләр никтер читләшәләр
Йөргән эздән, үскән нигездән.

Кабат җәйләр килер.
Маңгайларга

Бер тирән эз тагын өстәлер.
Еллар ага, ләкин без атлаган
Ызаннарда нинди эз калыр?

### *Без бит әллә нишләдек*

Күршеләрне дә белмичә,
Дуска сәлам бирмибез.
Эреләндек, масайдыкмы?
Белмим, әллә нинди без.

«Яңа байлар» байый диеп
Йөгерә-чабабызмы?
Ыштаннар ертык лабаса,
Белмибез чамабызны.

Хан сараенда үсмәдек,
Хан шәрабын эчмәдек.
Без бит болай түгел идек,
Хәзер әллә нишләдек.

Азынсак та, тузынсак та,
Хәлләребез хөрти лә.
Булганына шөкер кылып
Яшик әле бер көйгә.

### *Елларым, язмышларым*

Гомерләрне кәккүк саный,
Чакрым саен багана.
Без кичергән язмышларга
Ник битараф замана?
Баганалы озын юллар,
Олау-олау атлылар.
Баганасын юлаучылар
Кисеп утка яктылар.
Янды ялкынлы учаклар,
Янды гомерләре дә.
Юл буенда пыскып калды
Көлле күмерләр генә.
Сикәлтәле гомер юлы,
Сала юллары кебек.
Давыл кичергән замана
Тагын болганыр кебек.
Михнәттә үткән гомернең
Бу тәүге башы кебек.
Әйләнә дөнья, әйләнә,
Тегермән ташы кебек.
Борылмалы озын юллар,
Кайда микән азагы?
Кемнәргәдер тормыш иркен,
Кемгә дөнья газабы.
Зарланып ла зар бетәрме?
Кемнән гаеп эзлисең?
Без күрәсен кеше күрмәс,

Түз йөрәгем, түз, дисең.
Сабый чаклар кыска гына,
Гомер арасы кебек.
Биеккә үрмәли идек,
Маймыл баласы кебек.
Гомернең гамьсез чагы,
Яшьлекнең кызыл мәле.
Чишмәдәй акты гомерләр,
Узганы сизелмәде.
Максатымда күпме гамәл
Мин әле башкармаган.
Буыннарым какшаса да,
Зиһенем какшамаган.
Бүген дә яшьлек таңының
Юлларын үтәм әле.
Зур юллар кичкән гомернең
Йомгагын сүтәм әле.
Инде гомерем үренең
Җитмешенче баскычы.
Нинди куаныч, кулымда
Рухи дөнья ачкычы.
Ошбу серле мәгарәнең
Ишеген кердем ачып.
Язмышым – үрләр артында,
Максатым аермачык.
Кыйблама табан барам мин
Борылмалы юллардан.
Гомер йомгагым чуалган,
Очы кая югалган?
Бу җиһанның түрләре киң,
Үрләре сөзәк түгел.
Без табынган һәрбер бизәк
Гел асыл бизәк түгел.
Кузгалды заман арбасы,
Көпчәге шыгыр-шыгыр.
Дегете беткән көпчәкнең,
Кызганыч тавышыдыр.
Үзгәрде китте замана,
Чайкалып китте кебек.
«Үзгәртү» дигән затларга
Ышаныч бетте кебек.
Заманында корган нигез
Ишелә дә ишелә.
«Торгынлык»та үткән көннәр
Керә һәркем төшенә.
Ялганга корылган дөнья,
Ялганны сөйми күңел.
Ялган ялалар күтәреп
Акты да акты гомер.
И минем садә хисләрем,
Югалту, табышларым.
Сизмәдем гомер язымның
Көзләргә авышканын.
Балачаклар ятып калды
Юлларның тузанына.
Безнең эзләрне саклый күк
Кырларның ызаны да.

Борылмалы тормыш юлы,
Үрләре көйсез генә.
Кырылып бетте яшьтәшләр
Сугышсыз-нисез генә.
Күңелдә тик милләтемә
Биргән изге әманәт.
(Авыл буйлап гайбәт йөри,
Йөрәгемне яралап.)
Күпләрнең күңел тарлыгы
Рухымны кыса кебек.
Рухи гамәлем хакында
Эчләре поша кебек.
Нур булып дәште түренә
«Язмышым үзәннәре».
Шигъри сафлыкка табынган
Гыйззәтем үзгәрмәде.
«Тамырларым» бөреләнде,
Буыннар кала, димәк.
Иңнәренә таянырмын,
Чайкалып китсәм кинәт.
Буйсынып давыл иркенә
Ярсыды инешләрем.
Ярсулы еллар кичсәм дә,
Мин әле бирешмәдем.
И минем җылы почмагым,
И минем җылы түрем.
Саф мәхәббәткә табынып
Гомерләр иткән көнем.
Гүзәл мәхәббәт хакына
Канатым үсте минем.
Шул янып сөю ялкыны
Җырыма күчте минем.
Тик мәхәббәткә корылган
Тормышның гүзәллеге.
Җаным вә рухым белән дә
Үземдә сизәм моны.
Моны тоймаган йөрәкләр
Бозланган йөрәктер ул.
Андыйлар юктыр шикелле,
Булса да сирәктер ул.
Узган еллар иңсәсендә
Нинди эзләрем кала?
Инде гомерем кояшы
Төшлеккә төшеп бара.
Тик җанда тәүге кабынган
Мәхәббәт уты яна.

## ***Яшәү нигезе***

Җирдә күпме кеше яши,
Барысы да ипи ашый.
Ипи – яшәү нигезе ул.
Тик игенче бу халәттә
Язмыш белән берүзе ул.

Үзе чәчә, үзе ура,

Сукыр тиен ала шуңа.
Ә кышларын көне уза
Абзар-кура арасында.

Ипи – тормыш муллыгы ул,
Игенченең зурлыгы ул.
Бу хезмәтне санга сукмау
Замананың хурлыгы ул.

Шуңа күрә ачу чыга
Хакыйкатьтән качучыга.
Ипи бит ул һәркем өчен
Тормыш юлын ачучы да.

Бу тәгамнең бу җиһанда
Кыйммәте бар, зурлыгы бар.
«Ипекәйдән зур булма» дип
Дөрес әйткән борынгылар.

* * *

Кара болытлар куерып,
Дөнья калды кысанланып.
Күңелләрдә шом тудырып,
Җилләр йөри усалланып.

Табигатьнең үз кануны,
Үз гамәле зарур сыман.
Күк гөмбәзе, кара пәрдә,
Мәңге шулай калыр сыман.

Көнне төннән аерып булмый,
Күк белән җир тоташ кебек.
Авыр хисләр башны баса,
Гүя авыр бер таш кебек.

Тәңренекен кемнәр белсен,
Ни теләсә, шуны кыла.
Кыргыйлыкка, көферлеккә
Әле дә булса түзеп тора.

## *Елак гомер*

Шайтанның күзе сидекле булыр.

*Халык әйтеме*

Юк, билләһи, дөрес әйтмәгәннәр,
Гомерем буе мин дә елакмын.
Әле җирдә кеше булып яшим,
Шайтан булулардан еракмын.

Мин дөньяга елап туганмын да,
Елый-елый күзем ачылган.
Кендек әбием, кендегемне кисеп,

Бу җиһанга мине тапшырган.

Ятим бала булып үсәр өчен
Кирәкмәгән, бәлкем, туарга.
Кеше булгач, җирдә михнәт белән
Туры килде дөнья куарга.

Тормыш булгач, булды кайгысы да,
Тик әз генә булды шатлыгы.
Елый-елый үсеп буйга җиттем,
Мин – бер ятим малай актыгы.

Кайгыдан да елыйм үкси-үкси,
Шатлыктан да күңелем нечкәрә.
Әле дә шөкер, картлык көннәремдә
Куанычлар җанга өстәлә.

Үткәннәрне уйлап, төннәр буе
Елый-елый язам шигырьне.
Еламый ничек язмак кирәк
Газиз баштан кичкән гомерне?

Юктан гына сәбәп туып тора
Мин бичара елак юләргә.
Михнәт белән газиз гомерем узды,
Тик язмасын елап үләргә.

### *Күккә ашу*

Офык тарафына ялкын капты,
Кояш чыга үрләр артыннан.
Кояш белән гүя күтәреләм
Күңелдәге рухи ялкыннан.

Мәңгелеккә ашып барган кебек,
Биеклеккә күңел тартыла.
Шигырьләрем, кояш нуры кебек,
Дәва булсын иде халкыма.

Гүя кояш тарту көче белән
Үз артыннан мине күтәрә.
Максатыма менеп барам кебек,
Изге гамәлемне үтәргә.

Тойгыларым инде тугарылган,
Уй-хисләрем чиксез иректә.
Үзем атлыйм изге туфрак буйлап,
Рухым бии биек-биектә.

### *Имзасыз хат*

Каһәрләгән бер хат алдым бүген,
Ләгънәт чәчеп ята өстәлдә.
Ләгънәтләргә инде күнеккәнбез,
Каһәрләнгән илдә үскәнгә.

Юкны-барны язып ятасың, дип,
Берәү мине каты әрләгән.
Әрләнүдән түгел гарьләнүем,
Кеше язмышыннан гарьләнәм.

Күпме еллар гомер үтелгән дә,
Күпме юллар иҗат ителгән.
Өстәлемдә кара конверт ята,
Шуңа бераз күңел кителгән.

Усаллыклар эзли берәү миннән,
Усал ният булмый иҗатта.
Шигъри гамәл – ул бит хис гамәле,
Бикләп булмый аны йозакка.

Шигъри җанлы, ихлас күңелләрдән
Күпләр эзли никтер усаллык.
Очар кошлар кебек талпынамын,
Дөнья иркен, җанда кысанлык.

Өстәлемдә пычрак кәгазь ята,
Янау сүзе һәрбер җөмләдә.
Янаулардан куркып, хисләремне
Җыенмыйм мин әле җирләргә.

Шигырь язып яткан мизгелемдә
Бәйсез минем хисләр тезгенем.
Хиссез күңелләрне уятырдай
Тылсымлырак сүзләр эзлимен.

Агу чәчеп берәү хат җибәргән,
Тик куймаган никтер имзасын.
Имансызлар күп шул инде хәзер,
Кем дип атыйм хатның хуҗасын.

***Әҗәт***

Иван белән безнең йортлар
Бер очта.
Акча бирдем мин Иванга
Бурычка.
Бер-ике кат аннан сорап
Карадым.
Тик акчамны кире ала
Алмадым.
Иван белән безнең ара
Шәп иде.
Икебездә ике уртак
Гамь иде.
Якын дустым хәзер никтер
Югалды.
Айлар буе күрә алмыйм
Иванны.
Бер-беребезнең хәлебезне
Белмибез.
Йомыш-фәлән дип тә хәзер
Кермибез.

Мин – бер мәхлук, ә ул миңа
Бурычлы.
Гафу итә алмыйм шушы
Урысны.
Ни өчендер аның өчен
Оялам.
Качып йөрим хәзер үзем
Иваннан.
Оятымнан, ахры, шулай
Качамын.
Акча биреп, шәхси дошман
Ясадым.
Оят кача микән? Бәндә
Үзгәрә.
Дошманыңны әллә кайдан
Эзләмә.
Дусларыңны сынау юлы
Шул икән –
Тик әҗәткә акча биреп
Тор икән.

### *Якты эзләр*

Көзләр китәр, кыш та килер,
Язлар җитәр, карлар эрер.
Ел фасылы үзгәрсә дә,
Кабатланмас безнең гомер.

Кабатланмас ләкин гомер,
Кабат яшәү мөмкин түгел.
Өлешеңә тигән язмыш,
Өметләнмә күпне күңел.

Калсын нәсел, калсын тамыр,
Безне шулар искә алыр.
Җирдә якты эзләр калдыр,
Онытылмас сүзләр калдыр.

### *Бичарага ни чара?*

Бәяләр бәйдән ычкынды,
Бәйсез йөргән эт кебек.
Эт талаган күк талыйлар,
Алда өмет юк кебек.

«Яңа байлар» да ычкынды
Яшәеш тезгененнән.
Дөньяны күзли үзенчә
Комсызлык күзлегеннән.

Аласы бар, сатасы юк,
Безнең хәлләр бер чама.
Юк чарабыз, тик чабабыз,

Бичарага ни чара?

### * * *

*Каләмдәшем Габдулла ага Галиевка*

Әдип тә син, табиб та син,
Мәхәлләңдә имам да.
Күңелеңдә изге ният –
Тугры булу иманга.
«Хәзрәт малайлары» белән
Уралып үскән егет.
Ач үлемнән йолып калган
Яшәргә дигән өмет.
«Үкенеч»ләр дә булгандыр
Гомер агышларында.
Булгандыр истә калырлык
Кайгы-сагышларың да.
Дөньяда күпме гомерне
Үлемнән араладың.
Иҗатта сырхау җаннарның
Рухларын дәваладың.
Әдип тә син, табиб та син,
Сәләтең бар тумыштан.
Рухи дәрьяда йөзәсең,
Ләззәт алып тормыштан.
Бик күп әсәрләр язарсың,
Йөрәгең тынмас әле.
Бу кичәң тәүгесе түгел,
Соңгысы булмас әле.

### ***Яңгыр ява***

Табигатькә нәрсә булган?
Кыш уртасы, яңгыр ява.
Көннәр язга теләлгәндәй,
Еламсырап тора һава.

Әле тышта гыйнвар гына,
Башта кышкы уйлар гына.
Табигатьнең хәле мөшкел,
Шомландыра, уйландыра.

Тын буыла, җитми һава,
Тышта тоташ яңгыр ява.
Йөрәкләрдә авыр тойгы,
Йөрәкләрдә әрни яра.

Туган оя, үскән бишек,
Күкләр биек, күкләр тишек.
Җәберләсәк Җир-ананы,
Чит галәмгә китәр күчеп.

### ***Алданулар***

Апрель башы күптән узып китте,
Ә мин исә һаман алданам.
Әйтерсең лә гүя ошбу җирдә
Хак сүз сөйләр бәндә калмаган.

Күзләремә карап алдалыйлар
(Дөнья ялганына түз генә)
Дошман түгел, хәтта дусларның да
Телләрендә ялган сүз генә.

Җирдә «оҗмах» вәгъдә итә-итә,
Алдадылар «бөек» түрәләр.
Шуңа күрә җирдә күпме җаннар
Ялган белән гомер сөрәләр.

Алдадылар «якты киләчәк» дип,
Киләчәктән көттек өметне.
Юләр баш дип безне белделәрме?
Ялган белән шулай көн үтте.

Ялган сүзләр була яманнарда,
Яманлыктан булмый котылып.
Алданганыбызны белә торып,
Төп башында калдык утырып.

Айлар, еллар үтте, гомер үтте,
Аералмый хактан ялганны.
Хаклык өчен күпләр утка керде,
Хаклык диеп түкте каннарны.

Халык йоклый әле, милләт йоклый,
Йокысыннан кем бар уянган?
Җир йөзенең күпме бизәкләре
Ялган буяу белән буялган.

Ялган белән җирдә хаклык беткән,
Җәфа күргән бәндә яманнан.
Җир йөзенең һәрбер ертык җире
Ялган ямау белән ямалган.

Бәндәләргә шулай язгандырмы
Ялган белән гомер итәргә?
Алданулар әллә кирәк микән
Киләчәктән өмет көтәргә?

### ***Изге гамәл***

Шигырьләрне язамын мин
Төнлә белән.
Шигырь туа минем йөрәк
Түрләреннән.

Шул гамәлне кәсеп итеп
Яшимен мин.
Татлы газап кәсебенең
Җире бит мин.

Энҗеләрдән сүзләр тезә
Минем каләм.
Мин үземнән риза түгел
Әле һаман.

Һәр шигърем, дим, кеше күңелен
Бизәкләсен.
Тик берәү дә миңа яман
Сүз әйтмәсен.

Менмәсәм дә шигърияттнең
Үрләренә,
Ошбу гамәл минем йөрәк
Түрләрендә.

Күпләрнең бар хәрәм эше,
Яман эше.
Моңа ничек түзсен инде
Шагыйрь кеше?

Шигырьләрем булсын, димен,
Бизәк-бизәк.
Тик берәү дә таш атмасын
Миңа төзәп.

Каләмемдә бетте карам,
Шунысы яман.
Ә хәзергә сезгә әйтер
Сүзем тәмам.

## *Уйланулар*

Күпме кылган гөнаһыбыз,
Күпме кылган хатабыз.
Дөньялыктан мәңгелеккә
Әзерләнеп ятабыз.

Изгеме, яман шөгыльме
Гамәли кәсебебез?
Көферлеккә юлдаш булды
Зыялы нәселебез.

Хактан үткән, көфер киткән,
Ни көтә әле безне?
Язмышларга сылтамыйкмы
Бүгенге хәлебезне?

Ирексездән уйланасың,
Уйламый мөмкин түгел.
Иреклеккә сусасак та,
Дөньялар иркен түгел.

Кеше күңеле – изге күңел,
Кем этәрә этлеккә.
Кошларда да этлек бардыр,
Ябып куйсаң читлеккә.

## *Варислар*

Без гүяки беркем түгел,
Дөньялары иркен түгел.
Бу мәхшәрне сүзләр белән
Әйтеп бирү мөмкин түгел.

Кимсенүне, түбәнлекне
Күпләр үзе тели кебек.
Үз иркеннән түбәнсенеп,
Башын иеп йөри кебек.

Милләтебез – асыл заттан,
Аерылган ләкин хактан.
Шуңа күрә кимсетелә,
Җәберләнә төрле яктан.

Заманалар кырыс инде,
Хаким затлар урыс инде.
И милләтем, сынатмачы,
Сафланырга тырыш инде.

Кая табан агышыбыз?
Бәрәкәтсез табышыбыз.
Заманында шөһрәт алган
Бөек Болгар варисы без.

Безнең хәлләр тоткын кебек,
Киләчәкләр упкын кебек.
Безнең кебек мескен халык
Бу дөньяда юктыр кебек.

Заман кырыс, дөнья тар соң,
Таянырлык кемең бар соң?
Милләт өчен, халкың өчен,
Без янмасак, кемнәр янсын?

### ***Тизләнеш***

Күз алдында никадәрле
Үзгәреш.
Чаба заман, кот очарлык
Тизләнеш.
Машиналар чаба юлдан
Җилдереп.
Җилдереп, заман тизлеген
Сиздереп.
Бәндә башы белми никтер
Чаманы.
Әллә инде тәкъдир эзләп
Чабамы?
Бәндәләрнең юләрлеге
Юк түгел.
Тик заманның баганасы
Нык түгел.
Бу тизләнеш борынгыга
Яттыр ул.
Бабайларның әйткән сүзе

Хактыр ул:
«Әкрен барсаң, тиз барырсың», –
дигәннәр.
Ә үзләре тәпи-тәпи
Йөргәннәр.
Мул тормышта рәхәт гомер
Сөргәннәр.

### *Күләгәдә*

Күңелемдә зур хыяллар,
Зур өметләр өермәсе.
И күңелем, бу хыялый
Бәхеттән йөз чөермәче.

Тирә-ягым шау чәчәктә,
Күләгәдә җиләс һава.
Күңелемә зәңгәр күктән
Нурлар булып бәхет ява.

Карт алмагач яшь чәчәктә,
Каерылары кутырлаган.
Бу ышыкта кемнәр генә
Хыялланып утырмаган.

Бер уйласаң, көлке кебек,
Карт күңелдә нинди өмет?
Тик шулай да йөрәгем яшь,
Гүя үзем үсмер егет.

Якты уйлар, татлы хисләр
Баштан уза бер-бер артлы.
Җанда җырым бөреләнә,
Күгем аяз, гомерем татлы.

### *Хатирәләр*

Бик еракта калган хатирәләр
Әле дә искә төшә.
Күңел моңсулана, үткәннәргә
Һаман кучә-күчә.

Бүгенгенең үткән көнгә кадәр
Ерак аралары.
Яшь гомерен сагынып яшидер ул
Бәндә балалары.

Күңелемне һаман сихерле күк
Тәүге гармун моңы.
Бик озын да, бик кыска да кебек,
И син гомер юлы.

Тойгыларны чикләп булмыйдыр ул,
Һаман кабатлана.
Сизелмәде гомер, бу тормышны
Шашып яратканга.

Тормыш баскычлары биек икән,
Биек, катлы-катлы.
Хатирәләр һаман кабатлана
Никтер бер-бер артлы.

Балачакның бармы соң әле ул
Сагынып сөйләрлеге?
Хатирәләр булып истә калган
Яшьлек юләрлеге.

### *Бу мохиттә*

Фәрештәләр булып яралганбыз,
Кеше булып яшәп ятабыз.
Көн тууга, гөнаһ җыя-җыя,
Кабатланып тора хатабыз.

Сабый күңеле гөнаһлардан азат,
Сабый күңеле була изгедә.
Һәрбер инсан җирдә кем булуын
Үсеп буйга җиткәч сиздерә.

Җәмгыятьтән өстен булу авыр,
Бәндә заты моны тоядыр.
Җәмгыять ул – әхлаксызлык тулы,
Бозыклыкка баткан оядыр.

Саф акыллы кеше булмый, диләр,
Бозык заман, бозык мохиттә.
Фәрештәлек бездән качкан инде
Яңа дөнья, ерак офыкка.

Һәрбер кеше хаклы тик үзенчә,
Хакыйкатьтә була урталык.
Урталыгы кая хакыйкатьнең?
Бәндә башы калган буталып.

### *Мираслар*

Заманасы аңлау авыр хәзер,
Кем бар микән аны аңлаган?
Тормыш сикәлтәсен кичә-кичә,
Аңлар хәлләр башта калмаган.

Заман таркаулыгы,
Бәндә ялкаулыгы
Бирә әнә хәзер җимешен.
Авыр тойгыларны тоя-тоя,
Иж буеннан кайтып килешем.

Айлар, еллар өнсез үтәдер лә,
Әманәтләр кайчак үтәлер?
Бер ваемсыз таркау күңелләрне
Алда әле ниләр көтәдер?

Безгә бәхет кырын карады,

Байлыгыбыз бурлар талады.
Бүген әнә безгә трибунадан
Акыл сата заман карагы.

Иж буеннан җәяү кайтып киләм,
Еракларга китә уйларым.
Заманыны каргап яшәсәм дә,
Мин бу җирдән әле туймадым.

Тик китәрбез инде мәңгелеккә,
Дәвам булып калыр варислар.
Варисларга нинди мирас калыр?
Мирас булыр микән сагышлар?

### ***Кәмитләр***

Кәмит кенә уйнап йөрисе бар,
Эт өрдереп, кеше көлдереп.
Бүген әнә кәмит бакчасының
Җимешләре җитте өлгереп.

Дөнья иркен кебек, тормыш бөтен,
Эшләр гүя шуңа терәлгән.
Кәмит карап залда утырабыз,
Тамашаның хакы түләнгән.

Сәхнәләрдә кәмит, илдә кәмит,
Чикләү дә юк кебек, чама да.
Кәмитләрсез гүя яшәп булмый,
Шуңа охшап калды замана.

Тормышта бит төрле кәмитләр бар:
Ат кәмите, аю кәмите.
Кешеләргә кәмит зарур микән,
Буып торгач яшәү камыты?

Кәмитченең базар заманында
Базарлыгы күпкә югары.
Игенчегә, иген игүчегә
Андый хөрмәт илдә юк әле.

Кәмитчеләр аю биеткәннәр,
Бар халыкны җыеп мәйданга.
Әҗеренә кәнфит каптырганнар
Бу бичара мәхлук хайванга.

Табиблар да әйтә, диләр, ахры,
Кешегә, дип, көлү файдалы.
Гел елмаеп, көлеп яши кебек,
Илебезнең һәрбер аймагы.

Тук карынга көлү файдалыдыр,
Башка хәсрәт, гамең булмаса.
Көлә-көлә яшәп булмыйдыр ул,
Эчләреңдә бүре уласа.

Экранда да кәмит, сәхнәдә дә,

Һәр тарафта көлке кичәсе.
Үз-үзеңнән көлеп, ләззәтләнеп,
Калды, ахры, гомер кичәсе.

Бик булдыклы булып бу дөньяда
Яшәп булмый, Ходай кушмаса.
Көлә-көлә артка тәгәрибез,
Менә монысы кәмит ичмаса!

### *Күңел тәрәзәләре*

Акты гомер, акты еллар,
Сизелми дә актылар.
Елларым изге күңелгә
Күпме яла яктылар.

Тик минем күңел түрендә
Гөлләр чәчәк аттылар.

Саф гомерем, саф күңелем
Гөлләргә сердәш иде.
Гөлләргә сердәш булсам да,
Кемгәдер көндәш иде.

Иң якты хисләр кичергән
Тиңнәргә тиңдәш иде.

Хисләрем язгы ташкында
Ярсыган елга кебек.
Тормыш хәстәре күңелдә,
Ә күзем юлда кебек.

Хыяллар алсу офыкта
Балкыган нурлар кебек.

Еллар агышын күзлидер
Күңел күзләре генә.
Безмени, кем соң гаепле
Заман үзгәрүенә?

Тик башыма бәсләр салды
Гомер көзләре генә.

Акты гомерләр, шулай да
Үргә менәм, юлда мин.
Әйтерсең алга омтылган
Бәйгедәге юрга мин.

Юлларымда абындырып
Хурландырма, Ходаем.

Назлы көннәр, язгы җилләр

Тәрәзәмне кактылар.
Күңелдән җуйган тойгылар
Мине эзләп таптылар.

Таптылар да юлларыма
Затлы келәм яптылар.

### *Иблисләр*

Бер ләгънәтем – кеше хакын талый-талый,
Хәрәм белән гомер сөргән беришләргә.
Мең ләгънәтем – үз күңеленә тиң күреп,
Башкаларга пычрак аткан иблисләргә.

Бу җиһанга мәңгелеккә килгән кебек,
Үзләренчә гадел гомер сөргән кебек.
Яши алар, үз-үзенә бәя биреп,
Хәрәм малның игелеген күргән кебек.

### * * *

Ике фикер, ике акыл
Эш-гамәлләр чатында.
Һәрбер җанда бер үк тойгы
Булмый адәм затында.
Акылсызлар акыл сата
Акыл бирү хакында.

### *Меңнән бер киңәш*

Килсә сиңа берәр бәла,
Моны белә Хак Тәгалә.
Бирешмә син яман эшкә,
Бәла килсә, сыгылып төшмә.
Йөрәккәең әрнесә дә,
Сабырлыгың җуйма һич тә.
Утта янма, суга батма,
Ходай сине сынамакта.
Дошманнарың көнчелеге,
Куштаннарның «төчелеге»,
Корган уе аздырырга,
Хак юлыңнан яздырырга.
Хак Тәгалә юлын бозып,
Хәрәм малга кулың сузып,
Угрылыктан табып кызык,
Яши күрмә азып-тузып.
Һәр яманның эше ялган,
Тәгәридер түбән табан.
Ахирәттә хур булмассың,
Иманыңа тугры булсаң.
Үзе изге, үзе туры
Бердәнбер юл – Тәңре юлы.

Ахирәттә хисап көне –
Яманнарга учак түре.
Изге җаннарның, әлбәттә,
Урыны булыр җәннәттә.
Моны язу миңа лязим,
Инде тагынниләр языйм?!

### *Соңгы юл*

Күңелеңдә этлек булып,
Игелекләр булмый кылып.
Бу җиһанда этлек түгел,
Хаклык барын белми торып.

Ә шулай да күп вакытта
Затсыз җаннар була өстен.
Намус белән яшәсә дә,
Гакыллылар гүя мескен.

Гакыллыга юлдаш түгел
Азыну да, узыну да.
Күңелләре саф аларның
Хак Тәгалә хозурында.

Әгәр кем дә кәсеп итеп
Җыймак булса көфер малны,
Бу затларның ахирәттә
Җәһәннәмгә китәр җаны.

Кемдер хаким, кемдер ятим,
Һәммәбез дә Алла колы.
Һәр инсанның соңгы чиге,
Соңгы юлы – зират юлы.

### *Кырыслык*

Яшь чагымда юаш идем,
Дус-ишләргә юлдаш идем.
Һәрберенә кулым бирдем,
Түрләремдә урын бирдем.
Усал белән ярышмадым,
Уртак мал да табышмадым.
Тик шулай да соңыннан белдем,
Мин тормышта ялгышканмын.
Дошманнарны дус дип белеп,
Бергә йөреп гомер сөреп,
Мин бер юаш, тинтәк кебек
Яшәгәнмен икән элек.
Хәзер инде үзем кырыс,
Яманатым – Усал Урыс.
Кем дә миңа тел тидерсә,
Телем әче – әче борыч.
Юаш булсаң, битәрлиләр,

Кырыс сүзне күтәрмиләр.
Ни чарам бар? Кырыслыкка
Үзләре бит этәрделәр.

### *Иҗтимагый үзәк*

Иҗтимагый фикер,
Иҗтимагый үзәк.
Киребеткән булсаң,
Ук атарлар төзәп.
Юлларыңда тозак,
Телләреңдә йозак.
Телсез, юлсыз хәлдә
Яшәрсеңме озак?
Уйлан кабат-кабат,
Кыйблаңны яңарт,
Түрәләрне хурлап,
Була күрмә харап.
Хакны хаклама син,
Дусны яклама син.
Түрәләрнең данын
Берүк таплама син.
Кыяларың сөзәк,
Кеше рухын бизәп
Яши алмассыңдыр,
Иҗтимагый үзәк.
Илдә берлек, диген,
Илдә хөрлек, диген,
Оҗмахка тиң, татлы
Гомер сөрдек, диген.
Акны – кара, диген,
Караны – ак, диген.
Аңла тормыш серен,
Тыныч үтсен көнең.
Күңелең изге сыман,
Яшәр көннәрең бар.
Хаклык мөнбәренә
Кемнең менгәне бар?

### *Изге бурыч*

Шагыйрегез булып калыйм,
Тик шагыйрь булып кына.
Кошлар булып сайрар идем,
Талларга кунып кына.

Илһамланып яшим әле
Сезнең арада гына.
Шигырьләрем дәва булсын
Йөрәк яраларына.

Җан дәвасы бүләк итү
Минем изге бурычым.
Өметләрне акламасам,

Шагыйрьлегем корысын.

### *Упкын*

Әй Россия! Дөнья мәйданында
Сөйрәләсең көчкә-көчкә син.
Бер карасаң, «өлкән абый» да син,
Арык тәндә яман шеш тә син.

Җир куенында байлык, өстә байлык,
Утырасың байлык өстендә.
Ничек болай булды синең язмыш?
Ничек болай калдың мескенгә?

Акыл белән сине аңлап булмый,
Акылсызлык тамыр җибәргән.
Киләчәгең төпсез упкыннарның
Ярларына килеп терәлгән.

### *Юану*

Их, кайтырга иде малай чакка,
Атлар көтеп йөргән заманнарга.
Каршылыйсы иде ал таңнарны
Күксел томан яткан яланнарда.

Эчләренә дәшеп адаштырган
Урманнарда югаласы иде.
Күңелләрне ымсындырып торган
Офыкларга юл аласы иде.

Юлларымда мине озатып йөргән
Тургай моңы әле дә колагымда.
Тәүге хисләремне җанда тоеп
Юанырга калды, юанырга.

### *Хыял-аргамагымда*

Үрләргә китеп барышым,
Үрләргә илткән юлым.
Бер якта иген тирбәлә,
Бер ягым – хәтфә болын.
Гүяки Тәңрем җиһанны
Гөлләргә төргән кебек.
Хисләнәм, ошбу тарафны
Тәүге кат күргән кебек.
Нигәдер якты үрләргә
Мин сабый чактан менәм.
Тылсымлы тургай моңнарын
Гүя мин яттан беләм.
Бу минем изге кыйбламдыр,
Һәр ягым моңлы аваз.
Гүя изгеләр рухына

Биш вакыт кылган намаз.
Һәр изгегә бар яманы,
Хакыйкатькә – ялганы.
Җирдә хөрлек дигән идем,
Язмыш мине алдады.
Үрләргә җиталмадым шул,
Гомер ник тиз акты соң?
Татымый калдым ширбәтнең
Затлысын вә татлысын.
Гомерләр агышлары ла,
Йөрәкнең сагышлары.
Ялган ялалар яктылар,
Барыбер ябышмады.
Мал-мөлкәт колы түгел мин,
Рухият колы гына.
Кимсетелгән милләтемнең
Бер газиз улы гына.
Мал-мөлкәткә табынулар
Бу минем максат түгел.
Тик җирдә хисле җаннарга
Яшәве ансат түгел.
Үпкәләмим язмышыма
Мине алдаганына.
Мин һаман очам биектә
Хыял-аргамагымда.
Яшәгән саен күңелемдә
Дәрманым арта кебек.
Тик арттан килеп кемнәрдер
Итәктән тарта кебек.

## ***Безнең тормыш***

Тыңламадык картлар әйткән сүзләрне,
Олыгая төшкәч, зиһеннәр үзгәрде.
Аңламадык изгелеккә юл барын,
Дөньялыктан мәңгелеккә – бер адым.

Бер максатсыз эш кылабыз,囧штә без,
Сөйрәләбез шуңа көчкә-көчкә без.
Яңаны кормый, искене сүтәбез,
Кай тарафтан, кемнән ярдәм көтәбез?

Үз-үзебезне аңламаган бәндә без,
Кыйблабызны табалмаган хәлдә без.
Безнең язлар сандугачсыз яз кебек,
Безнең тормыш иңә барган саз кебек.

## ***Күнегәсең икән***

Күнегәсең икән тормыштагы
Һәр яманга, күнегәсең икән.
Изгелекләр өмет итә-итә,

Хыялларга күмеләсең икән.

Кеше күңеле хыял белән яши,
Күңелендә якты өмет кенә.
Ә ул өмет офык артындагы
Күренеп киткән чаткы кебек кенә.

Күнегәбез һәрбер каршылыкка,
Күнегүнең чиге күренерме?
Кемгә табыш, кемгә ачы язмыш,
Кемнәр аңлар синең күңелеңне?

Күнегәсең икән түрәләрнең
Буш вәгъдәләр белән алдавына.
Чама хисен җуйган каракларның
Күрәләтә илне талавына.

Тормыштагы мәкер-золымнарга
Ничек түзә микән изге күңел?
Йөрәкләрнең сызлануын тоеп
Узып бара инде газиз гомер.

Түзеп була икән күкрәгеңдә
Әрнеп торган канлы яраларга.
Түзеп булмый ләкин йөрәгеңне
Телгәләгән ялган ялаларга.

### *Урманнардан урап кайтам*

Онытыламын кайвакытта,
Юл буйлап китә-китә.
Урмандагы һәрбер аваз
Йөрәгем аша үтә.

Илаһи нинди гүзәл бер
Киң җиһанның почмагы.
Гүзәллекне җырга салып
Җырлый җырчы кошлары.

Адаштым серле сукмакта,
Камашты карашларым.
Урманда адашсам да мин,
Язмышта адашмадым.

Урманнардан урап кайтам,
Кайтыр юлым бер генә.
Йөрәгемдә бөреләнгән
Тәүге җырым өлгерә.

### *Афәт*

Аракылар эчеп үткән заман,

Көмешкәләр эчеп үскән заман.
Өмет кыйблабызны табалмыйча,
Кулыбыздан эшләр төшкән заман.
Урамнарда аунап ятмасак та,
Яманатың һәркемгә дә мәгълүм.
Якты дөньяларны томалады,
Сихерләде шул аракы мәлгунь.
Кемдер эчте бер сәбәпсез генә,
Кемдер эчте сылтап заманага.
Ләкин менә кем дә алынмады
Шул афәттән илне араларга.
Еллар үткән саен, замандашлар
Сирәгәйде генә, сирәгәйде.
Газиз җаннар искә төшкән саен,
Йөрәктәге яра тирәнәйде.
Кыйблабыздан искән саф җилләрнең
Тоймый калдык җанны назлаганын.
Без туздырдык хезмәт тиеннәрен,
Ә кемнәрдер чәчте казна малын.
Замананың бозык бәндәләрен
Изге җаннар диеп атыйбыздыр.
Алар иҗат иткән «оҗмахлар»ның
Җимешләрен бүген татыйбыздыр.
Еллар узган саен, бу афәтнең
Ах-зарлары күбрәк ишетелә.
Нигезендә хәмер яткан тормыш
Төшергәндер безне шушы көнгә.

### *Былбыл*

Былбылга тылмач кирәкми,
Һәр милләт телен белә.
Таң тууга, һәр күңелне
Моңнарга күмелдерә.

Әнкәсеннән откан көйнең
Тик үзе белә серен.
Заманага сылтау итеп
Бутамый ана телен.

Талга куналмас иде ул,
Моңга уралмас иде.
Кунар таллары булмаса,
Былбыл булалмас иде.

Шигырьдә дә былбыл кебек
Булып каласы иде.
Һәр милләтнең күңеленә
Юллар табасы иде.

Һәммә кошның үз авазы,
Күпләр аны аңламый.
Таш бәгырьле бәндәләргә
Былбыл ни дә карга ни.

Таңда былбыл җырын суза,

Чишмәдәй ургылдырып.
Яшәргә иде бу җирдә
Бер моңлы былбыл булып.

### *Баганалы юллар*

Баганалы юллар, баганалы
Кала белән авыл аралары.
Шул юллардан тәпи-тәпи атлап
Йөри идек авыл балалары.

Сөйли идек урыс телен ватып,
Ипи ала идек, катык сатып.
Замананың авырлыгын татып,
Үтеп китте безнең үсмер вакыт.

Ул каланың кибет пулатлары,
Озын була иде чиратлары.
Без арага кереп ипи алсак,
Ярсый иде кала ир-атлары.

Сатучылар үз гамәлен үти,
Киштәләрдә без үстергән ипи.
Шул елларда, буразнага ятып,
Ачка үлде Хәерниса түти.

Тормыш шулай гел бер көе иде,
Безнең хәлләр бигрәк хөрти иде.
Безне күргәч, кала малайлары
Бармак төртеп һәрчак үрти иде.

Заман башка хәзер, тормыш бүтән,
Кала юлын машинада үтәм.
Гомеремнең хәтер җебен сүтәм,
Онықларым ышанырлар микән?

### *Гомерләр кичәсең дә*

Җирдәге хәлләр мәгълүмдер
Җиде кат күк катына.
Җирдә мәхшәр, нидер җитми
Һаман бәндә затына.
Тәлинкәләргә утырып,
Галәм чикләрен гизеп,
Илчеләр килеп кисәтә,
Безнең хәлләрне сизеп.
Керләнде заман, керләнде,
Табигый төсен җуеп.
Күпләр яши үз асылын
Югалту хисен тоеп.
Хәләл көч, хәләл хәзинә
Һәркемгә тигән чама.
Чаманы югалтканнарга
Бармы соң берәр чара?
Хакыйкать, хөрлек дигәннең
Асылы ялган аның.

Җиде кат күкләр катына
Һәр таңда ялварамын:
«И Ходаем, бир сабырлык
Бәндә балаларына.
Һәр ялганнан, һәр яманнан
Безне арала гына.
И Раббым, җирне сафландыр
Шифалы һаваң белән.
Җир йөзе авыру, сихәтлә
Тылсымлы дәваң белән».

*** * ***

Яшьлек дәрте ташып торган чакта,
Хис-тойгыга мавыгып яшәдек.
Еллар бусагасын атлаганда,
Хатирәләр торды яшәреп.

Тормыш ваемыннан кача-кача,
Гомер узды, сүнде өметләр.
Күпме омтылсаң да, үткәннәргә
Кайтып булмый икән, егетләр.

Безгә дөнья назлары тимәде,
Игәүләде тормыш игәве.
Теләк-ниятләрне йөгәнләде,
Максатларга ирек бирмәде.

### *Тәкъдир*

Без кичергән заман – шаулы заман,
Бертуктамый торды үзгәреп.
Шау-шуларны җанда тоя-тоя,
Үткән гомерне дә сизмәдек.

Балачаклар калды һай еракта,
Үткән еллар шавы колакта.
Җирдә кунак кына без, янәсе,
Гомер узды гүя кунакта.

Хушлашырга күпме вакыт калган?
Бәхилләшү кирәк үзара.
Ни дияргә инде бу тәкъдиргә?
Гомерләр бит үтте нужада.

### *Гомерләр узып бара*

Күңелемдә кайвакытта
Мең төрле уйлар туа.
Гомерләр үтә сизелми,
Замана арттан куа.
Дөньяның шатлыклары ла,
Дөньяның аклыклары.
Нинди күркәм бу тарафның
Сафлыгы, пакьлекләре.
Тик күңелнең була кайчак

Әрнегән вакытлары.
Уянса зифа талларым,
Уянса бөреләрем,
Гүя мин дә, бөреләр күк,
Кояшка үреләмен.
Кояшка үрелергә дә
Нур булып түгелергә.
Кешеләргә якты булсын –
Шул минем күңелемдә.
Шатлыктан исерсәм дә мин,
Кайгылар кичерсәм дә.
Сабырым җитәр, сызланмам,
Тау-ташлар күчерсәм дә.
Күнегелгән бу тормышның
Югына, барлыгына.
Үртәләнәм берәүләрнең
Күңеле тарлыгына.
Җирдә күпме игелек бар?
Йомгагын сүтеп кара.
Теләсәң-теләмәсәң дә,
Гомерләр үтеп бара.

### ***Утсыз ялкын***

Һәркемгә дә тигез юкса
Җирдә яшәү хаклыгы.
Кемгәдер тормыш газабы,
Кемгә яшәү шатлыгы.

Хаклыгымны аклыймынмы?
Исбат итә алмадым.
Бу дөньяда мәкер барына
Яши-яши аңладым.

Яши-яши аңладым, тик
Соңардым кебек менә.
Йөрәгемдә ялкын түгел,
Пыскыган өмет кенә.

Яшәсәк тә тормыш йөген
Иңебездә күтәреп.
Кайсыбыз соң хак гамәлне
Төгәл генә үтәдек?

Һәр күңелнең үз гаме бар,
Һәр күңелнең үз хисе.
Бар бит кайбер хиссезләргә
Рухи дәва өстисе.

Әйтерсең лә күңелемне
Утсыз ялкын айкаган.
Билгесезлек дәрьясында
Мин дә гүя чайкалам.

### ***Бакча гөлләре***

Яр буенда бәбкә үләне,
Өй артында бакча гөлләре.
Табигатьнең бар бит серләре,
Гөлләрнең дә була төрләре.

Бакчалардан хуш ис тарала,
Кыргый гөлләр үсә арада.
Тик нигәдер алар тоташтан
Бер-беренә никтер охшашкан.

Балкып тора бакча гөлләре,
Гөл гомеренең җәйге бер мәле.
Үссәләр дә нурга тартылып,
Күзләрендә кала талкынып.

Өй артында бакча гөлләре,
Кайберләре була энәле.
Бакча гөлен кыргый гөлләрдән
Аера белмәгәнбез элгәре.

Мин нигәдер гөлләр язмышын
Кеше язмышына охшатам.
Җил-давыллы салкын кышта да
Күңелемдә гөлләр кышлатам.

Без дә үстек нурга тартылып,
Яз гөлләре кебек талпынып.
Һаман-һаман үргә үрләдек,
Тик арада күпме хиссез җаннар,
Туң йөрәкләр барын белмәдек.
Бер үк бакчаларда үссәк тә,
Бер туфракта гомер итсәк тә.

## ***Соңладым***

Мин тормышны соңрак белдем, ахры,
Ә туганмын җиргә иртәрәк.
Тик нигәдер язмыш кануннары
Юлларымны торды киртәләп.

Йөрәгемдә гүя тоям кебек
Бәхет гөлләренең сулганын.
Хыял үрләренә җиталмамдыр,
Соңладым шул, ахры, соңладым.

Һәр кылганның җирдә үз сәгате,
Тормыш җырым кайчан язылыр?
Гомер көзләренә килеп кердем,
Ә бу, бәлкем, бәхетем языдыр.

## ***Үрләр***

Тауларга мендем.
Ташына

Утырдым түбән карап.
Сихри дөнья киңлегенә
Сокландым кабат-кабат.
Биектән ачык күренә
Дөньяның асыл төсе.
Бер халәттә бу төсләрне
Тоймыйдыр һәрбер кеше.
Шундадырмы берәүләрне
Биеклек тарта микән?
Монда кояш соңрак баеп,
Иртәрәк калка икән.
Тик бирудә юк яшеллек,
Тоташтан җансыз кыя.
Монда таңнарда сайраган
Кошлар да кормый оя.
Бөркетләр генә сыенган
Таш-тау араларына.
Бөркет булырга язмаган
Бәндә балаларына.
Ник мин дә әле үрләргә,
Тауларга күтәреләм.
Юкса гомрем узып бара
Тауларның итәгеннән.
Үрләрдән карап сокланам
Елга дулкыннарына.
Түбән төшәм, түзалмыйча
Йөрәк сулкылдавына.
Язмышым үзәннәрдәдер,
Мондадыр җылы оям.
Шуңамы монда гына мин
Үземне иркен тоям.
Үргә мендем, түбән төштем,
Иңнәремдә биштәрем.
Тик шулай да үз чамамнан
Түбәнлеккә төшмәдем.
Киң җиһанның хөрлегенә
Үземчә минем караш:
Кырларда күзең камашсын,
Урманга кереп адаш.
Мин гүя йөрәк җырымны
Дөньяга ишеттерәм.
Гомеремнең көзе килде,
Үрләрдән төшеп киләм.

## ***Эзләнү***

Төн утырып шигъри юллар тезәм,
Төннәрдә мин никтер үзгәрәм.
Таң беленеп, көнгә авышса да,
Һаман язам, һаман эзләнәм.

Бер шагыйрь дә әле әйталмаган
Яңа фикер эзлим, яңалык.
Зиһенемме таркау? Әйтер сүзем
Бер-беренә тормый ялганып.

Телебезме әллә фәкыйрьләнде,
Башка телләр белән буталып?
Ялкыныбыз сүлпән, янмыйбызмы
Ятлар учагыннан ут алып?

### *Иләк*

Иләде тормыш, иләде,
Нечкә булды иләге.
Ятим бала бу димәде,
Җанга тынгы бирмәде.
Күпләргә бәхет-сәгадәт
Юклыгына төшенәм.
Ач-ялангач балачакны
Һәр көн искә төшерәм.
Бабамнарны да иләгән
Шул иләмсез җиз иләк.
Инде безнең буынга да
Дәвамы калган, димәк.
Иләде соң, әй иләде
Бу замана иләге.
Кемдер безне каһәрләсә,
Кабул булды теләге.
Текәдер тормыш үрләре,
Ник соң эти дәшмәде?
Илдән качып, яшь кәләшнең
Назын татып яшәде.
Булмады тормыш терәге
Әллә шуңа күрәме?
Балачак-дөнья назыннан
Бер өлеш тә тимәде.

### *Елмаюлар*

Ихластан елмаюлар бар,
Мәкерле елмаюлар.
Ирексездән елмайганнар,
Дөньяга сыялмыйлар.
Кемнең күңеле мәкерлектә?
Кемнең күңеле изгедә?
Бер караштa бу икәүне
Аерып булмый тиз генә.
Бу ике зат бер-беренә
Юлдаш түгел тамчы да.
Ни кызганыч, күп очракта
Мәкерлек өстен чыга.
Тик шулай да еллар узгач,
Чын хакыйкать ачыла.

### *Азатлык хакына*

Азатлыкка сусап,

Тоткын кошка охшап,
Уздылар гомерләр, киселде өметләр.
Азатлык хакына
Утларда яндылар,
Башларын салдылар сөлектәй егетләр.

Дөньялар болганды,
Киләчәк томанлы,
Билгесез язмышлар әрнетә күңелне.
Офыклар түрендә
Алсулык күренә,
Азатлык кояшы балкышы түгелме?

Милләтләр язмышын
Хурлаган, кимсеткән
Намуссыз затларның шөһрәте үсәрме?
Азатлык хакына
Әйләнә, ахрысы,
Әйләнә, әйләнә замана күчәре.

## *«Яңарыш»ка**

Бәйгеләрдә чапкан юрга кебек,
Бу якларга килеп кердең дә,
Максатларга якты маяк булып,
Урын алдың халык күңелендә.

Еллар узган саен нурланасың,
Фикердәшләр әнә нихәтле.
Һәрбер сүзең җанга якын синең,
Һәрбер сүзең җанга сихәтле.

Кемдер безне синнән араласа,
Кемдер кылса сиңа яман эш,
Кыргыйлыкны Ходай гафу итмәс,
Йолып калыр сине «Яңарыш».

## *Язгы аклык*

Күктә йөзә ак болытлар,
Читләре киртләч кенә.
Ябырылып ак кар яуды
Яз килеп җиткәч кенә.
Алмагач һәм чияләрнең
Ишелде өсләренә.
Шәрә ботаклар әйләнде
Ак чәчәк төсләренә.
Бу нинди могҗизалар ла,
Бетмәстәй карлардыр ул.
Кайдадыр офык артында
Адашып калгандыр ул.
Һәр гамәлнең үз мәле бар,

Һәр фасылның үз төсе.
Күңелләргә юкса аклык
Өстисе дә өстисе.
Ләкин бу иләс күңелнең
Язга ымсынган чагы.
Яз сылуның әмеренә
Бар да буйсынган чагы.
Тагын бер кыш узып китте,
Гомернең ап-ак кышы,
Ә урамда әле һаман
Яз белән кыш тартышы.
Якты кояш та елмаер,
Ямьләнер якын-тирә.
Гомерне ашыктырабыз,
Артына тибә-тибә.

### *Шомлы көннәр*

Кояш баешының алсулыгын
Серле болыт томалаган иде.
Көнбатыштан килгән кара кайгы
Күңелләрне урап алган иде.

Кеше хәтере чикле, тик шулай да
Сыкрый һаман йөрәк, әрни күңел.
Ярты гасыр гомер узылса да,
Ул көннәрне онытырлык түгел.

Без сабыйлар идек, бу мәхшәрне
Аңлар хәлдә түгел идек әле.
Тик шулай да бераз үсә төшкәч,
Безнең башка төште дөнья гаме.

Ач-ялангач узган балачаклар,
Ул көннәрне әле дә онытмадым.
Бүген энә якты тәрәзәдән
Аяз күккә карый оныкларым.

Май иртәсе җиңү алып килде,
Шомлы көннәр әле дә күңелләрдә.
Язмышыбыз аяз күгебезне
Урамасын иде сөремнәргә.

### *Буталышлар*

Хак вә ялган, ахры, дуслашкандыр,
Җитәкләшеп йөри торгандыр.
Дөньялары шуңа буталадыр,
Килер көннәр серле томандыр,
Ахырзаман җитә торгандыр.

Аланнарым яшел юргандыр ла,
Атлар утлап йөри торгандыр,
Нахак сүздән күпләр башын җуйды,
Без, ахрысы, соңгы корбандыр.
Заманага нәрсә булгандыр?

* * *

Күп ишеттек инде гайбәт сүзне,
Ишетәсе килә әйбәт сүзне.
Кемдер, бәлкем, яманатны сатып,
Төгәллеккә чакырадыр безне.

* * *

Акылың кыска, күңелең бозык,
Гомер иттең азып-тузып.
Диндар булып карт көнеңдә
Үзгәрүең бигрәк кызык.

* * *

Күңел елдам, өмет – зурдан,
Ымсынып гомер үтә.
Әйтерсең лә туасы көн
Ал таңнар вәгъдә итә.
Алданганны белә-белә,
Алданып гомер үтә.

* * *

Телең бетте, динең бетте,
Кайда соң кыйммәтең?
Чукынасың гына калды,
И газиз милләтем.

## *Шифаханә ятагында*

*Әгерҗе район шифаханәсе табибларына*

Әтәчләр дә уятмыйлар,
Таңнар сәер монда.
Төрле уйлар уйлап ятам
Шифаханә ятагында.

Язмыш мине зур бәлагә
Салмасмы дип курка төшәм.
Монда чин да, түрә дә юк,
Һәммәбезгә уртак түшәм.

Уйландыра, шомландыра
(Булмас димә үлем-китем).
Тик шулай да шөкер әле,

Рухым көчле, акылым бөтен.

Бу йөрәкләр күпме күргән
Кимсенүләр, җәберләрне.
Күпме ялган, нахак яла
Телгәләгән бәгырьләрне.

Авыру хәлен кемнәр белсен?
Белсә белер табиб кына.
Шөкер инде, дәвалыйлар
Җан җылысын салып кына.

Җылы сүзләр җанга дәва,
Бәлаләргә тарыганда.
Йөрәкләр бит назга мохтаҗ,
Коткаралмый дару гына.

*** * ***

*Шагыйрь Фазыл Шәехкә*

Китабыңны кулга алдым, дустым,
Ак битләрен кат-кат актарам.
Бу дөньяда инде кем бар икән
Гүзәллектән ләззәт тапмаган?

Балачактан бергә җырлап үттек
Хыял тауларының итәген.
Үргә менгән саен, күбрәк күрдек
Бу дөньяның серле икәнен.

Канатларын җилләр каерса да,
Шагыйрь халкы туры сүзлерәк.
Хафаланма, дустым, син бит әле
Күзле бәндәләрдән күзлерәк.

## *Хәтер*

Хәтердән җуелган нигәдер
Яшьлектә ятлаган исемнәр.
Бу кеше үткәнен оныткан,
Ваемсыз яшәгән, дисеннәр.

Күпләрнең авылдан, нигездән
Нәселе, тамыры йолкынган.
Яшьлектә бергәләп үссәк тә,
Никадәр исемнәр онтылган.

Безме ул, туфракка табынып,
Язмышка, тәкъдиргә инанган?
Калага агылды кешеләр,
Күпләре яздылар иманнан.

Хәтердә чәчәкле болында
Атларда җилдереп йөргәнем.
Кемнәрдер онытты кемлеген

«Әни» дип ачылган телләрен.

Без бит ул караңгы көннәрнең
Михнәтен, газабын татыдык.
Кешеләр иманын җуймады,
Авылда яшәде татулык.

Хәтердә черегән бәрәңге,
Кычыткан ашаган заманнар.
Кемнедер исемнән җуйсам да,
Ул көннәр онытылмый калганнар.

### *Ак хыял*

Ак хыялым ал таңнарда
Тирбәлә рәшә кебек.
Ул мине чиксез-кырыйсыз
Җирләргә дәшә кебек.

Диңгездә кораб тирбәлә,
Ак хыялдай ак җилкән.
Җилкәнне җил ега, диләр,
Хыялны ега микән?

Ак хыялым, ак канатым,
Давылларга тиң көче.
Ак хыялын юрга итеп
Дөнья гизә ир кеше.

### *Җырлар яздым*

Төннәр буе утырып җырлар яздым,
Җырларымны кемнәр гаепләр?
Гаепләрләр, бәлкем, туң йөрәкле
Рухи сукыр, рухи гарипләр.

Күп йөрәкләр, ахры, күгәргәннәр,
Шигъриятне, моңны сизмиләр.
Тик шулай да һаман, ярсый-ярсый,
Җырларымнан ертык эзлиләр.

Сандугачлар җырлар һай сузамы?
Гомерләр соң җырсыз узамы?
Һәр күңелнең җирдә үз моңы бар,
Тыңламыйбыз гына без аны.

Җыр – милләтнең асыл хәзинәсе,
Күпме йөрәк шуңа табынган.
Аерылалмый кеше, аерылалмый
Бу табигый сихри агымнан.

Җырчы дигән даным булмаса да,
Моңсыз түгел минем йөрәгем.
Ятлар арбасына утырмадым,

Ятлар җырын җырлап йөрмәдем.

Тоя белсәң әгәр, дөнья безне
Илаһи бер моңга ураган.
Әле дә шөкер, җирдә үз моңым бар,
Үз җырым бар, шуңа куанам.

### *Бер ялгышым*

Бер ялгышым мең кузгата
Йөрәктәге яраларны.
Онытылды инде дисәм,
Туып тора яңалары.

Бер ялгышны мин яшерсәм,
Күпме сагыш җыеп яшим.
Эчтән генә көеп йөрим,
Гаебемне тоеп яшим.

Мин кайгыда, кая хөкем?
Ялгышларга хөкем бармы?
Бер ялгышым – мең газабым,
Акланырга хакым бармы?

Насыйп түгел инде, ахры,
Хафаланмый, янмый йөрү.
Бер януга мең теләктер
Ялгышыңны аңлый белү.

### *Чарасызлык*

Хыялымда иңнәремә
Таш-таулар күтәрәмен.
Ваемсыз замана килде,
Шуңамы үртәләмен...

Сүземне ярып салырлык
Бармы соң ышанычым?
Тик җирдә яшәмимен мин
Кемгәдер ошар өчен.

Максатларга җитәсем юк,
Гомерләр узган инде.
И йөрәгем, ни чараң бар?
Сызлан да сызлан инде.

### *Ходай кичерерме?*

Ишәйде инде, ишәйде,
Тулып түгелде малың.
Көчәйде инде тавышың,
Еракка китте даның.

Масаюыңа чама юк,

Чөелде борының да.
Хан сарае салып кердең
Иске йорт урынына.

Калмады синдә намус та,
Кешелек кыйммәте дә.
Килешми хәрәм, килешми
Мөхәммәт өммәтенә.

Дөнья гаме юк башыңда,
Комсызлык уе гына.
Максатым янау түгел һич,
Кисәтеп кую гына.

Туганнарыңны оныттың,
Күтәрдең танавыңны.
Ләкин Ходай кичерерме
Кешеләр талавыңны?

### *Тамыр*

Уйга калып гүя басып торам
Мин гомеремнең тәүге чатында.
Алтмышны да инде узып киттем,
Җитмеш яшь тә күренә якында.

Имин генә еллар бусагасын
Алтмыш тапкыр инде атладым.
Хәтеремдә һаман атлар көтеп
Болыннарда йөргән чакларым.

Тик шулай да гомерем кояшына
Иртәрәктер әле баерга.
И язмышым, мине көн дә туган
Мәшәкатьтән, зинһар, аерма.

Еллар узган саен, тормыш йөген
Күндәмрәк тарта барамын.
Нинди гаҗәп: яшем алга чаба,
Үзем никтер артка каламын.

Ә шулай да замандашлар белән
Йөрим әле кеше санында.
Үзем үлсәм, оныкларым кала,
Бөреләрем кала тамырымда.

### *Дошманнар*

Бер дошманым кинәт вафат булды,
Гөнаһына кермим үлгәннең.
Тик мин аның, үзе исән чакта,
Изгелеген белми йөргәнмен.

Мине күрсә тәмам ярсый иде,
Очкынланып янды күзләре.
Ул явыз җан ничә еллар минем
Һәр эшемнән гаеп эзләде.

Еллар үткән саен, һаман-һаман
Яманлыгын торды сиздереп.
Ул бит, миңа этлек эшлим диеп,
Кылган икән күпме изгелек.

Кешегә бит тәнкыйть кирәк, диләр.
Яши-яши мин дә көйләндем.
Эчә идем, эчүемне ташлап,
Иң гүзәл бер кызга өйләндем.

Тик моннан соң мине яман итеп
Гаепләргә инде базмагыз.
Дошманының тырышлыгы белән
Рәтле кеше булды абзагыз.

Гомеремдә тагын ни күрермен,
Белеп булмый Ходай кушканны.
Ул вафат шул инде, тагын менә
Кайдан табыйм шундый дошманны?

### ***Базарда вөҗдан сатылмый***

Тәгәрмәчләр тук-тук килә,
Күпләр тирән йокыда.
Бер төркем пенсионерлар
Кайталар бер купеда.
Кайталар татлы, ләззәтле
Уй-тойгылар кичереп.
Хезмәттә үткән елларын
Сагынып искә төшереп.
Тик арада бер түбән җан
Сөйләшә өстән карап.
Һәрбер сүздән гаеп табып,
Җан телә кабат-кабат.
Кем ни белән көн үткәрә?
Кем керемле эш белә?
Кем эшли күпме чумара? –
Берәм-берәм тикшерә.
Кайчандыр бу бер әртилдә
Мөдир булып эшләгән.
Комсыз булган, кырыс булган,
Әмма эше пешмәгән.
Заманында булган, диләр,
Бик каты бәгырьле адәм.
Саф намуслы кешеләрне
Кимсеткән, җәберләгән.
Арадан бер карт шул вакыт,
Шушы, диеп, кәсебем,
Күрсәтте үзе ясаган
Гади эшче рәсемен.
Бу рәсемгә күчкән гүя
Аның йөрәк ялкыны.
Илаһи бер сихри нурга
Вагон эче балкыды.
Иҗатчының һәр хезмәте –
Вөҗданы кушкан бүләк.
Базарда вөҗдан сатылмый,

Бирмиләр акча түләп.
Җирәнгеч караш ташлады
Абзый шулчак эшчегә.
Әйтерсең лә агу чәчте
Серле рәсем өстенә.
Бер мыскыллы кыргый хәлдә
Карады ул рәсемне.
Әллә инде күзләреннән
Утлы ялкын чәчелде?
Сүз тапмадым бу бәндәгә
Кем диеп дәшәргә дә.
Бюрократ бюрократ икән
Пенсия яшендә дә.

### *Зур ышаныч*

Әхмәдине рәис итеп куйдылар,
Ышанычны аклар диеп уйлыйлар.
Тәкъдим итте аны район вәкиле,
Алга китәр, диде, колхоз әртиле.
Алдыр-гөлдер, алдыр-гөлдер гөлләре,
Эшләр бераз шәбрәк иде элгәре.
Иллә инде газиз башның күргәне
(Ни чуртымамыни дөнья кирәге).
Хәмер катыш үтә кайбер көннәре.
Шул булдымы зур ышаныч, күр әле,
Колхозны ул соңгы чиккә терәде!
Сүзләр йөри, ул, диләр, «үсәсе»,
Китеп барыр, тәмам тулгач кесәсе.
Телгә кергән халык сүзе хак була,
Яманлык та өскә чыккан чак була.
Каян килә мондый хәлләр дигәндә,
Бигрәк комсыз булып чыкты бу бәндә.
Азмы-күпме эшләп алган арада
Фатир алды, дача салды калада.
Авылдашлар әле ярый аңлыйлар,
Әхмәдине бу эшеннән алдылар.
Тик шулай да ышаныч зур кешегә,
Никтер аннан йөз чөерми берсе дә.
Бу түрәне, хөрмәт итеп шулкадәр,
Әле дә булса уч төбендә йөртәләр,
Тиздән аны райүзәккә алдылар.
Райүзәктә һәйбәт эшләр бар, диләр.
Ә хәзер ул – бер базаның мөдире.
Бу мөдирдән ни чыгасы билгеле...

### *Мәкер*

Һәр күңелнең була ышанычы,
Була таянычы.
Саф булып та акланмаган гомер
Бигрәк аянычлы.

Гаепсездән кимсетелгән йөрәк
Әрни яра сыман.
Кара мәкер яши пычрак эзләп
Тырнак арасыннан.

### *Төзәлде китек күңел*

Үткән көннәрнең берендә
Син исерек түрә идең.
Үзеңне диңгез гизүче
Корабтай күрә идең.

Сөрем катыш әмер бирдең,
Һушымны алды бу көн.
Канатымнан каннар саркый,
Хисләрем генә бөтен.

Ник соң үзең сизмәдең син?
Җилкәнең чыпта иде.
Җил-давылларны кичәм, дип,
Сөйләвең юкка иде.

Борчулы көннәр санаулы,
Төзәлде китек күңел.
Намусым белән шаярдың,
Язмышым белән түгел.

### *Дулкыннар җыры*

Иж суы ага, дулкынын
Ярларга кага-кага.
Кырларда булган хәбәрне
Иделгә алып бара.
Яшел яулык болгап гүя,
Хәерле юллар теләп,
Яр буендагы тирәкләр
Тирбәлеп куя кинәт,
Таңнарыңда ярларыңа
Җилләр орынып уза да,
Кырда дулкын, суда дулкын
Серләшәләр үзара.
Бездән дә өлеш булсын, дип,
Эшләрне тизләтүгә.
Дулкыннар гүя дан җырлый
Игенче хезмәтенә.

### *Замана караклары*

Без авылда сабый вакыттан ук
Намус белән яшәп өйрәнгән.
Тик нигәдер заман караклары
Ычкындылар бүген йөгәннән.

Дөньяларны залим түрә басты,
Гамәлләре нурсыз, савапсыз.
Этләр дә бит сөяк урлап чаба,
Яши алмый сөяк-санаксыз.

Түрәме син җирдә, хакимме син,
Һәркемнең бит гомере бер генә.
Шуны аңламаган наданнарга
Тоттыралар никтер дилбегә.

Халкым өйгән асыл хәзинәне
Өсләренә басып талыйлар.
Ярый әле күңел, җан сафлыгын,
Кеше рухын талый алмыйлар.

Зарланып ла, ай-һай, зар бетәрме,
Гомеркәйләр әрнеп үтәрме?
Йа Ходаем, заман каракларын
Тәхеткә соң кемнәр күтәрде?

### ***Изгелек кыл***

Булса синең изге ният
Күңелеңдә,
Яман белән якалашма
Гомереңдә.

Әйләнеп уз, юлларыңда
Ятса елан,
Изгелекне юлдаш итеп
Яшә, олан.

Яшәсәң дә игелексез
Заманнарда,
Изгелек кыл җәфа салган
Яманнарга.

Сөйләсеннәр бу нинди бер
Мескен, диеп.
Бу мескеннән без никадәр
Өстен, диеп.

Яманнарның һәрбер сүзе
Яла булыр,
Намуслыкның йөрәгенә
Яра булыр.

Мәрхәмәт кыл аналарга,
Аталарга.
Залимнәргә ыштыр булып
Хаталанма.

***Кешелеккә***

Егерменче гасыр узып бара,
Кай тарафка атлый кешелек?
Һәлакәткә юллар эзли мәллә?
Һич кенә дә булмый төшенеп.

Чиксезлеккә юллар яра-яра,
Күкләр, ахры, бетте тишелеп.
Җир-ананы рәнҗетмибез микән,
Шул турыда уйлан, кешелек!

Болай да бит кылган гөнаһлардан
Бәла-каза килә ишелеп.
Тәңребезнең кодрәтеннән узып,
Кая узынасың, кешелек?

Корабларга утырып, башка галәмнәргә
Китмәбез бит инде күченеп.
Җир-ананың кадерен белеп яшик,
Акылыңны җуйма, кешелек!

***Казанымда апрель азагы***

Мин сәфәргә төнлә чыгып киттем,
Авылым калды тирән йокыда.
Мин Тукайга килдем, Казаныма,
Мәйданнарда шигырь укырга.

Хөрмәт итеп мине, колач җәеп
Каршы алды Казан вокзалы.
Урамнарда инде гөлләр үскән,
Казанымда апрель азагы.

Яңа йортлар үскән ни арада,
Мәркәзебез инде үзгәргән.
Хуҗаларча горурланып атлыйм
Бөек Тукай йөргән эзләрдән.

Тик нигәдер урыс чиркәүләре
Котырынып бүген чаң кага.
Тукай рухы иңгән изге көндә
Урысларда нинди тантана?

Даң-доң, даң-доң, шомлы чаң тавышы,
Сискәндерә якын-тирәне.
Явыз Иван әллә, яу кубарып,
Казаныма кабат киләме?

Әйтерсең лә мәхшәр, замананың
Чаң телләре бәйдән ычкынган.
Шушы шау-шу гүя Тукайны да
Тын тыкрыкка кертеп постырган.

Иминлеккә генә булса иде
Чиркәүләрнең шашып ярсуы.
Кайтканыма күпме айлар узды,

Ә колакта шомлы чаң чыңы.

### *Юлбасарлар*

Юлбасарлар юлда кеше талаганнар,
Тик шулай да дөнья хәлен аңлаганнар.
Әрәмтамак, комсызларны сөймәгәннәр,
Әмма ярлы-ябагайга тимәгәннәр.

Хәзер менә бу рәхимсез заманада
Кемнең генә каерылмаган канатлары?
Мәгънәсез бер комсызлыгын тыялмыйча,
Һаман талый әле заман каракләры.

### *Мөстәкыйльлек*

Белмим, никтер асылын тоймаганмын
Гомер буе кылган эшемнең.
Мин бу җирдә нигә яшәвемне
Бүген генә гүя төшендем.

Әйтерсең лә безне ничә гасыр
Буып торган кыршау өзелде.
Тышауларын өзеп дулап чапкан
Юрга кебек тойдым үземне.

### *Яз, каләмем, яз әле*

Бу дөньяда гыйбрәт хәлләр азмы соң?
Шулай булгач ник, каләмем, язмыйсың?
Бер затлы сүз төшми синең очыңнан,
Зиһеннәрне, ахры, җилләр очырган.
Тәбәнәкме әллә түбәм, түшәмем?
Үз хәлемнән, ахры, түбән төшәмен.
Бүгенгене телдә генә сөйләсәк,
Гафу кылмастыр безләрне киләчәк.
Чарасызлык башларны әйләндерә,
Кемнәргәдер бу дөнья бәйрәм генә.
Бер ваемсыз яши кайбер бәндәләр,
Бу яшәүдән ни хикмәт, ни мәгънә бар?
Дөньясында күпме ишәк, надан бар,
Барысы хаким, түрә булып калганнар.
Шул ишәкләр итәкләрдән тотадыр,
Болай булса дөнья тәмам буталыр.
Һәр кылганның хәерлеме азагы,
Шулай булгач, яз, каләмем, яз әле!

### *Тормыш юлларында*

Яшь чагында ниләр кичерсәң дә,
Җиңел генә уза.

Тик шулай да җиңел кергән маллар
Бик күпләрне боза.

Кемнәргәдер бәхет яшьли килә,
Ә кемгәдер соңлап.
Ә берәүләр яши ләззәтләнеп,
Кеше хакын урлап.

Җиңел кергән малдан масаерга,
Тилерергә иртә.
Очрый әле тормыш юлларында
Кырык катлы киртә.

Бер уйласаң, гомер юллары бит
Кыска гына ара.
Ни әйтсәң дә, тормыш арбасы ул
Үз юлыннан бара.

Бу дөньяда бәхет-сәгадәтнең
Сукмаклары тар соң.
Өлешеңә тигән куанычлар
Карт көнеңә калсын.

### *Нинди холык*

Күк гөмбәзе тулып-тулып,
Җиргә тияр-тимәс булып,
Дулкынлап килсә болыт,
Аш була игеннәргә дә,
Хуш килә күңелләргә.

Бар дөньяны җимерер булып,
Җил-давыллап килсә болыт,
Шау-шулар тиккә инде,
Өметләр көтмә инде.

Җил-давыллап килгән болыт
Бер котыра, бер тына.
Бу гадәтне охшатам мин
Юкка-барга дулап йөргән
Эшкуарлар холкына.

### *Чит ярдагы якын дустым*

Бозлар агып киткәч, һәр көн иртән
Киләм дулкыннарга баш ияргә.
Хискә чумып йөрим Иж буенда,
Берәү кармак сала каршы ярда.
Кырыс көзләр җиткәч, саубуллашып,
Кулыбызны болгап хушлашабыз.
Мин – бу ярда, ә ул – каршы ярда,
Язлар җиткәч кабат очрашабыз.

Арабызда дулкын, ара ерак,
Тавышыбызны җилләр алып китә.
Бер-беребезне һәр көн сәламлибез:
«Хәерле көн, кордаш, тыныч иртә!»
Ул үзе бер өлкән генә бәндә,
Үзем белмим аның исемен дә.
Тик шулай да һаман арта бара
Бер самими дуслык хисе миндә.
Күңел тынычлана чын йөрәктән,
Ихлас аралашу кыйммәтеннән.
Үзем гади генә бер татармын,
Ә ул, ахры, удмурт милләтеннән.
Хискә чумып йөрим Иж буенда,
Керсез күңелләрдә күпме наз соң?
Чит ярдагы якын дустым белән
Күп язларда очрашырга язсын.

### *Ыштыр*

Кыштырдыйлар кыштыр-кыштыр
Киндер күлмәк, киндер ыштыр.
Син булганда җанга җылы,
Шәфкатьләрең киңдер, ыштыр.
Уңае бар, уңасы юк.
Ыштыр барда туңасы юк.
Кирәк икән – уңнан ура,
Кирәк икән – сулдан ура.
Уңайлыгын, рәхәтлеген
Кем ураган, шуннан сора.
Кидек киндер күлмәкләрне,
Кидек киндер ыштаннарны.
Ләкин менә җенем сөйми
Ыштыр йөзле куштаннарны.

### *Золым*

Рухымны җаһилләр таптаган,
Күгемне болытлар каплаган.
Нигәдер хыялый күңелемнең
Туасы таңнары атмаган.

Рухият кояшым сүнәр дип,
Гомерләр узадыр борчылып.
Әйләнә-тирәмдә вәхшиләр,
Әйләнә-тирәмдә тынчулык.

Кайда соң хаклыкка тугрылык,
Заманның тезгене кемнәрдә?
Канатлар имгәнде, киселде,
Очарга талпынып йөргәндә.

### *Давылны юксыну*

Буранны, давылны яманлап

Яздым мин шигыремдә, җырымда.
Давылга юлыгып, нигәдер
Күп вакыт адаштым юлымда.

Юлларда адашкан күңелем
Ничек соң шигырьгә тап булды?
Ул минем караңгы тәнемнең
Хыялый таңнарын аттырды.

Язын да, хәтәрле көздә дә
Агылды, агылды шигырьләр.
Буранлы, караңгы төннәрдә
Яктыра бардылар күңелләр.

Тик бүген кыш белән язларның
Әйтерсең мәйданда тартышы.
Куалый давылны, куалый
Кояшның илаһи балкышы.
Күңелем нигәдер ашкына,
Давылны юксына, ахрысы.

## *Авырып алдым*

Авырып алдым, көйсезләнеп калдым,
Көйсезләнәм сабый бала кебек.
Үз-үземне белми үрсәләнәм,
Көйле дөньям артка кала кебек.

Еллар узган инде, гомер узган,
Тик шулай да килми сер бирәсе.
Күзем юлда, гүя минем кулда
Замананың ефәк дилбегәсе.

Бу вакытлы гына бер мизгелдер.
(Кемнәр белә инде дөнья хәлен?)
Күп җаннардан, бәлки, хислерәктер
Авырып яткан, янып яткан мәлем.

Авырып алдым, көйсезләнеп калдым,
Буыннарым сызлый сулык-сулык.
Гомер буе шулай интексәк тә,
Тормышта без калыйк кеше булып.

## *Язмышлар*

Тирәкләр астында күләгә,
Чебешләр тибенә үләндә.
Каргалар сагалый тирәкне,
Шомлы хис телгәли йөрәкне.

Чебешне язларда барлама,
Язмышлар үзәне түбәндә.
Тормышның серләре тирәндә,

Тормыш ул – мәкерләр капчыгы.

Давыллар селкетә тирәкне,
Язмышлар җилкетә йөрәкне.
Вәхшигә бәхетләр елмайган,
Йа Раббым, җаннарга бир мәйдан.

### *Авыр хәбәр*

*Якын дустым Дамир Сираҗет-*
*диновның якты истәлегенә*

Син гармунчы идең, һәр күңелне
Моңга күмү иде теләгең.
Йөрәклардән чыккан авыр хәбәр
Тетрәндерде Тирсә төбәген.

Җеназаңда синең булалмадым,
Куялмадым чәчәк кабереңә.
Син авылда моңлы бала идең,
Аерылдың бездән мәңгегә.

Килсә дә бит гомер сөрәсе,
Бар күңелне гөлгә күмәсе.
Кеше гомере чикле, һәркемнең дә
Бар бит әле гүргә керәсе.

Хафаланма, дустым, туфрагыңда
Изге җаннар дога кылырлар.
Бездән калган газиз буыннар
Җирне сөреп иген урырлар.

Гармуныңның моңын отар өчен,
Өй каршыңа кунар таң кошы.
Таңнар булып тәрәзәңнән керер
Офыкларның алсу балкышы.

Җеназаңда синең булалмадым,
Шушы авыр хәбәр кичегеп.
Шигырь язам менә, бергә узган
Гомерләрне баштан кичереп.

### *Китап сүзе*

Борынгылар, изге китап алып,
Сәфәрләргә чыгып киткәннәр.
Китап сүзе хак сүз була, диеп,
Хаклык белән гомер иткәннәр.
Китап тотып антлар иңдергәннәр,
Китап тотып тәүбә кылганнар.
Изге гамәлләрне юлдаш итеп,
Исән-имин генә торганнар.
Китап тотып әйтәм: бәндәләрне
Адаштырды заман шаукымы.
Изге юлдан түгел, күпләребез
Китте көфер юллар аркылы.
Көфер затлар шактый ишәйде шул,

Изгеләргә хөкем кылына.
Гакыллының тотып телен кисә,
Тозак куя йөргән юлына.
Көферлекнең тугры юлдашы юк,
Җирдә кала пычрак эзләре.
Үз асылыңа кабат кайтыр булсаң,
Ярдәм итәр китап сүзләре.
Киштәләрдә күпме хәзинә бар,
Кем соң аны хәзер укыган?
Уяныгыз, газиз милләттәшләр,
Саташулы серле йокыдан.
Кулыгызга китап алыгыз да,
Күзләрегез киңрәк ачылыр.
Китап битендәге һәрбер сүзләр
Гаделлекнең тәүге башыдыр.
Җирдә кеше яши бу тормышның
Изге гамәлләрен үтәргә.
Гакылсызга гыйлем юлдаш түгел,
Гыйлем кирәк дөнья күтәргә.
Хәләл гомер кылган изгеләрнең
Дәвамына калган буын сез.
Табыныгыз изге китапларга,
Гаделлеккә юлдаш булырсыз.

## ***Мәҗнүннәр***

Гакылы сәламәт кеше
дөнья малына кызыкмас.

*Халык әйтеме*

Җанга үтә комсызларның
Явызлыгы.
Комсызларның булмыйдыр ул
Авызлыгы.
Бу затларның яманаты
Телдә була.
Яман чире гомере буе
Бергә була.
Яман затлар уйлый байлык
Хакында ул.
Байлык өчен өйләнә бай
Хатынга ул.
Үз иркеннән акча колы –
Мәҗнүн була.
Бер гыйфритне яр итәргә
Мәҗбүр була.
Аермый ул хәләлне дә,
Хәрәмне дә.
Газиз гомере үтә аның
Караңгыда.
Мәхәббәтнең ышанмый ул
Барлыгына.
Дөнья малын җыя һаман
Сандыгына.
Бу мәхлукның бармы икән
Уйланганы?
Тар ләхеткә сыяр микән
Җыйган малы?

### *Учаклар*

Сәхрәләргә чыгып учак яксаң,
Пыскып сүнә аның күмере.
Пыскый-пыскый бары да янып бетә,
Шуңа охшаш кеше гомере.
Учак сүнә, ләкин көле кала,
Гөлләр үсә яккан урында.
Кеше дә бит җирдән китеп бара,
Җыры кала килер буынга.
Мин дә, ахры, тиздән югалырмын,
Картлык килде, әрни буыннар.
Юксынырмы мине учак яккан,
Ялгыз печән чапкан урыннар?
Тик теләмим ләкин бу дөньядан
Эзсез-нисез генә китәргә.
Мин үземә изге бурыч алдым,
Шул бурычымны телим үтәргә.
Сизелми дә гомер узып китте,
Тормыш йөген иңгә күтәреп.
Тик нигәдер изге теләкләрең
Тормый икән бары да үтәлеп.
Бәлкем, җирдә озак торырмын да
Сезнең белән бергә булырмын.
Әтиләре эшкә чыгып киткәч,
Сабыйларын карап торырмын.
Сәхрәләргә чыгып учак яксам,
Сүнмәс, бәлкем, минем учагым.
Оныкларым килсә, каршы алыр
Җәеп җылы ялкын кочагын.
Тик һәркемнең соңгы язмышына
Чик сызыгы күптән сызылган.
Пыскый-пыскый бары да янып бетә,
Тәкъдир җитә, гомер узылган.
Пыскып янган көлле күмер кебек,
Килми әле никтер сүнәсем.
Оныкларның учак тергезгәнен
Килә әле минем күрәсем.

### *Соңгы юл*

Күңелеңдә этлек булып,
Игелекләр булмый кылып.
Бу җиһанда этлек түгел,
Хаклык барын белми торып.

Ә шулай да күп вакытта
Затсыз җаннар була өстен.
Намус белән яшәсә дә,
Гакыллылар гүя мескен.

Гакыллыга юлдаш түгел
Азыну да, узыну да.
Күңелләре саф аларның
Хак Тәгалә хозурында.

Һәр бәндәнең хак гамәле
Хәләл гомер итүендә.
Бу җиһанда һәрбер гамәл
Бары да Тәңре хөкемендә.

Әгәр кем дә, кәсеп итеп,
Җыймак булса күфер малны.
Бу затларның ахирәттә
Җәһәннәмгә китәр җаны.

Кемдер хаким, кемдер ятим,
Һәммәбез дә Алла колы.
Һәр инсанның соңгы чиге,
Соңгы юлы – зират юлы.

### *Тукай рухы, заман агышы*

Мин шигырьдә Тукай булалмадым,
Яшем җитте алты дистәгә.
Тик шулай да, еллар узган саен,
Тукай рухы миңа өстәлә.

Хыялымда гүя чабам кебек
Тукай иярләгән атларда.
Күпләр бүген олы бәя бирә
Аның кебек асыл затларга!

Шушы затлар милләт хәзинәсе,
Милләтемнең асыл кыйбласы.
Сәйдәшсез дә, Тукайсыз да булса,
Нишләр иде татар дөньясы?

Иртә таңнан китәм Иж буена,
Шунда йөрим көннәр буена.
Бу якларда бөек Тукайның да
Эзе калгандыр күк тоела.

Мин Тукайны яшьли хөрмәт иттем,
Ул бит безнең рухи пәйгамбәр.
Шигырьләрсез яши алмыйдыр ул
Аның рухын җанда тойганнар.

Заманасы күпме кимсетсә дә,
Асрамага мине бирмәгән.
Тик шулай да ошбу шигъри дөнья
Күңелемне никтер биләгән.

Шигырьләрем кеше күңелендә
Үз асылын тапсын, үз төсен.
Милләтемнең шигъри сандыгына
Өлешемне килә өстисем.

Яңа чорга аяк атлап кердек,
Ерак калды Тукай заманы.
Тик бүген дә никтер шагыйрьләрнең
Йөрәкләре әрнү, яралы.

Тукай үзе бөек зат булса да,
Язмыш аны никтер алдаган.
Керләнепләр беткән, ләкин үзе
Бу дөньяны пакьли алмаган.

Мин үзем дә дөнья куа-куа,
Тормыш баткагына күмелдем.
Гөнаһсыз да түгел, тик шулай да
Бу хурлыктан хали түгелмен.

Мин гомеремнең тәүге көннәрендә
Күпне күргән, күпне майтарган.
Ялгышларым булса, аклар өчен
Үткәннәргә кире кайталмам.

Тукай рухын йөрттем йөрәгемдә,
Хаклык булды минем терәгем.
Кешеләрнең ачы язмышына
Мин битараф була белмәдем.

Еллар уза, кайчак керсез күңел
Яла-ялган белән таплана.
Календарьның битен актаргандай,
Гомер юлын еллар актара.

Бер сәбәпсез җанны телә генә
Бу тормышның хагы-нахагы.
Саф хисләргә, керсез күңелләргә
Кемнәр бирер гадел бәһане?

### *Төш*

Төш дисәң төш,
Мин төшемдә
Булдым зур түрә, имеш.
Затлы зиннәткә төренгән
Әйләнә-тирәм, имеш.
Берәү дә мине борчымый,
Беркем дә бозмый мазам.
Мин хаким түрә булсам да,
Шигырьләр, җырлар язам.
Мемуарлар да язгалыйм,
Сызгалыйм ара-тирә,
Булсам да үзем зур хаким,
Тәхеткә ия түрә.
Йөгереп йөри нәширләр,
Әйләнә-тирәм тулып.
Иң бөек шагыйрь гүя мин,
Туганмын даһи булып.
Күптән онытылган кешеләр
Киләләр күз алдыма.
Мәрхүмә әбиләр йөри
Сөйләшеп үзалдына.
Йөгрешеп йөри вәзирләр,
Өяләр дөнья малын.
Көннән-көн арта мөлкәтем,
Көннән-көн арта даным.

Ташыйлар затлы ризыклар,
Тау кадәр алтын, көмеш.
Бәхет кояшым елмая,
Һаман да балкый, имеш.
Уянып киттем берзаман,
Күрәм – бары да искечә.
Ышанмыйм, гүя утырам
Тәхетемнән төшмичә.
Төштә күргәнне уңайга
Юрарга ярый микән?
Өнле дөнья фани микән?
Төшләнү фани микән?
Ышанмыйм, тышта ни бар?
Иртә түгел, кичтер ул.
Бу җиһанда яшәү үзе
Өнгә охшаш төштер ул.
Көтмәгәндә хаким булу
Чикле генә эштер ул.

### ***Хакимнәргә***

Тәхетләргә менәр өчен
Хезмәт кирәк.
Тормыш дигән дәрьяларда
Йөзмәк кирәк.
Җиңел генә тапкан бәхет
Бәхетмени?
Әрсезләнеп менгән тәхет
Тәхетмени?
Әрсезләнеп түрә булды
Кайберегез.
Шуңа күрә борчулы да
Кайгылы без.
Үҗәтләнеп түргә менгән
Хакимнәр сез.
Ошбу сүзем – йөрәгемнән
Әйтелгән сүз.
Һәр гамәлне үтәү өчен
Талант кирәк.
Тумышыңнан Тәңре биргән
Канат кирәк.
Тормыш назын, саф хисләрне
Урладыгыз.
Сезләр корган җәмгыятьнең
Корбаны без.
Һәр гамәлне Тәңре үзе
Кыла хөкем.
И хакыйкать, сине ничек
Исбат итим?

### ***Таңнарга каршы барамын***

Офык ягы алсулана,

Тиздән якты таң туар.
Яшел болын киңлегендә
Утлап йөрер мал-туар.

Таңга каршы юлга чыктым,
Чыклы үләнне ерып.
Канатланам, бар тарафны
Кочып алырдай булып.

Җиләс һава – җанга дәва,
Шифалы да, татлы да.
Сулаганда, күңелемдә
Яшәү ямен арттыра.

Каен кызлары үрелгән,
Болытларга сузылып.
Таң җилендә назланалар,
Гүя иркә кыз булып.

Таңнарга каршы барамын
Яшьлек сукмагым белән.
Тик яшьлекнең, йөгерә-йөгерә,
Каршы чыкмавын беләм.

### ***Яңа ел килә, Яңа ел***

Яңа ел килә, Яңа ел,
Төренеп бәсләр белән.
Сизелми дә үтә гомер
Мәшәкать, хәстәр белән.
Кыш бабай да юлга диеп
Чыккандыр куышыннан.
Күлләр туңды кышның хәтәр
Зәһәрле сулышыннан.
Яңа ел килә, яңа ел,
Күңелләр нигә китек?
Каһәрле, шомлы заманда
Кайгыны уртак итик.
Рәнҗетү, җәберләүләргә
Калмасын иде урын.
Болай да хәтәр юл үтте
Безнең чор, безнең буын.
Нахакка үртәмик җанны,
Җаннар бит җәрәхәтле.
Шәфкатьлелектә генә бит
Тормышның бәрәкәте.
Шаулашып, гөрләшеп үтсен
Яңа ел кичәләре.
Рәтләнер барыбер дөнья,
Рухыбыз исән әле.

### ***Тузан бөртеге***

Галәм күзлегеннән караганда,
Без бу җирдә тузан бөртеге лә.

Шуңа, ахры, безнең язмышлар да
Тузан бөртегедәй бөтерелә.

Кендегебез белән береккәнбез,
Без бу җирнең газиз балалары.
Тигез түгел ләкин һәркемнең дә
Яшәү белән үлем аралары.

Хакыйкатьтә кемнең кем булуы
Күренә инде тормыш мисалында.
Кемдер яши җирдә җәфа чигеп,
Кемдер яши кеше хисабына.

Бер-береңнән беркем өстен түгел,
Бу чынбарлык диеп санаганда.
Без бу җирдә тузан бөртеге лә,
Галәм күзлегеннән караганда.

## *Дуска*

Сүз иреге диеп тугарылма,
Телчә телне тыеп буламы?
Түрәләрне хурлап сүз сөйләсәң,
Тыңлап торыр шымчы колагы.

Мөстәкыйльлек диеп бик масайма,
Хисләрнең дә була тезгене.
Тайпылып та китеп бер атласаң,
Күреп алыр дошман күзлеге.

Без ирекле диеп хыялланма,
Буш куыктай безнең хыяллар.
Авызыңа йозак эләрләр дә
Таш капчыкка тыгып куярлар.

## *Сыкрый урман*

Эчләренә кергәч адаштырган
Урманнар да бетте талкынып.
Ярым черек төпләр арасыннан
Яшь куаклар килә калкынып.

Кошлар да юк инде, җәнлекләр дә,
Бу бушлыктан качып беткәннәр.
Корткычлыкны Ходай кичерерме?
Һай аяныч безнең үткәннәр.

Шәрә калган урман сукмагыннан
Тыныч кына ничек узасы?
Бабамнардан калган мирас иде,
Бармы аның хәзер хуҗасы?

Урманнарга кердем, айкап йөрдем,
Табалмадым чалгы сабы да.
Телгәләнде җаным, сыкрый урман,
Үткәннәрен гүя сагына.

### *Бер авыру сүзләреннән*

Авырып ятам, тышта этләр
Өрә кебек.
Күршеләрем хәл белергә
Керә кебек.
Хәл белергә килер, бәлкем,
Туганнар да.
Авыруымны ишетсәләр
Урамнарда.
Мең төрле уй чуалгандыр
Авыру башта.
Чирнең дә бит сере башка,
Төре башка.
Була җирдә чума чире,
Үләт чире.
Бик күпләрдә була торган
Йөрәк чире.
Комсызлыкның башы булган
Акча чире.
Ни кызганыч, бу авыруның
Булмый чиге.
Төрле уйлар уйлап ятам
Үзалдыма.
Килмәсеннәр мине ләкин
Кызганырга.
Кем килсә дә, яман уйдан
Араласын.
Кызганычка калган түгел
Минем көнем.
Агачлар да яфрак коя
Көзләрендә.
Моңсу гына сагыш кала
Үзләрендә.
Язлар җиткәч, бөреләре
Терелә дә,
«Без исән» дип, ал кояшка
Үрелә дә,
Һәр ботакның яфрак иңә
Иңнәренә,
Өмет килә язның матур
Көннәрендә.
Язлар җиткәч, мин дә әле
Савыгырмын,
Язга кадәр җитәр минем
Сабырлыгым.
Авыруымнан, сагышлардан
Бушанырмын.
Дус-туганның кемлегенә
Ышанырмын.

### *Табигатьнең үз кануны*

Күкләргә генә сыешмый,

Куерды кара болыт.
Күк иләгеннән иләнеп,
Коела яңгыр булып.

Кояш та күктән югалды,
Гүя офыкка төшеп.
Ник карасын бер генә тик
Болыт пәрдәсен тишеп.

Яңгыр ташкыны чиләкләп
Түгелә җир өстенә.
Күкләр җиргә тоташканмы?
Җирдә нурсыз тас кына.

Тукта, яңгыр, бу гамәлең
Хәзергә җитеп торыр.
Туктамасаң, игенчеләр
Игенне ничек урыр?

Кая кояш? Ник күренми?
Юксынды күптән күңел.
Болай булса, авыл халкы
Кышларга ничек керер?

Табигатьнең үз кануны,
Үз эшен тирән белә.
Хафага да сала, кайчак
Нурга да кинәндерә.

### *Озын гомер теләмәгез миңа*

Озын гомер теләмәгез миңа,
Мин ризамын Ходай биргәненә.
Ике кеше гомере яшәсәм дә,
Җитә алмам тормыш үрләренә.

Йолкып кына ташлап буламы соң
Йөрәгемнең җөйле ямауларын?
Сизенеп лә торам тәкъдиремнең
Бармак селкеп миңа янаганын.

Хәтеремдә, уңга-сулга бәрелеп,
Тормыш диңгезендә кайнаганым.
Әле дә шөкер инде, азмы-күпме
Иҗат итү юлын сайлаганмын.

Олыгайдым гына, картаймадым,
Картлыкка да инде күпме ара.
Еллар ергалаган җилкәннәрне
Чал дулкыннар комлы ярга кага.

### *Этлекләр*

Күз алдымда шәйләнәдер
Вәхши җаннар шәүләсе.
Эткә диеп мылтык атсам,
Дуска тияр ядрәсе.

Сафланырмы дип уйласам
Шакшы дөнья чүплеген.
Акланмый гына өметләр,
Илдә этләр этлеге.

Томанлыдыр бу гомернең
Һәр сәгате, һәр көне.
Айга карап улый энә,
Улый этләр төркеме.

Хакыйкатьтән өстен бүген
Һәр бозык, кыргый гамәл.
Кемгә хәрәм, кемгә хәләл,
Юктыр һич аерыр әмәл.

Тәхетләргә үрмәләде
Күпме адәм актыгы.
Ил өстенә этлек кылып,
Каплыдылар яктыны.

*** * ***

Таңга каршы озын юлга чыктым,
Аргамагым затлы, иярле.
Язмышымнан качыйм дигән идем,
Кара сакал арттан иярде.

## ***Җәйге иртә***

Офыкта ал нурлар балкышы –
Томанлы иртәнең ал төсе.
Туачак өметләр яктысы,
Хыялның татлысы, татлысы...
Сирпелде кояшның нурлары,
Җиһанга изге көн юллады.
Илаһи сихерле серле моң
Тирбәлә югары, югары.
Таң җиле орынды гөлләргә,
Диңгездәй чайкалды үзәнлек.
Хисләрнең бәйгесен өзәрлек
Гүзәллек, гүзәллек, гүзәллек.

## ***Язмышым үзәннәрдә***

Үрмәле гөлләр сарышкан
Үрләрне менеп барам.
Түбәндә, үзәндә калган
Җирләрне күреп барам.
Биеккә, биеккә дәшә
Канатлы хыялларым.
Мин бу җиргә, ахры, бер дә
Сокланып туялмамын.
Челтер-челтер чишмә ага

Таш-таулар арасыннан.
Күңелдә сагыш кузгала,
Юксынган бала сыман.
Мин кичә генә гүя бер
Дөньяны белгән бала.
Нигәдер сизелми үткән
Үрләргә менгән ара.
Табындым үрмә гөлләргә,
Сокландым гүзәлләргә.
Яшьлегем үтте үрләрдә,
Язмышым – үзәннәрдә.

### *Шофер дуска*

Шофер дустым, беләм якты
Уйларыңны.
Чәчәкләргә бизәр идем
Юлларыңны.
Барыр юлың озын синең,
Үрләр биек.
Шул үрләрдә туктап калма,
Арыдым, диеп.
Тынгысызлык юлдаш сиңа,
Тынгысызлык.
Син барасың матур-матур
Җырлар сузып.
Юлларыңда хәвеф-хәтәр
Булмасын ла.
Яшел утлар дәшеп торсын
Үр башына.
Минем җырым канат бирсен
Хыялыңа.
Гөлчәчәкләр юлдаш булсын
Юлларыңда.

### *Шигъри дәва*

Кирәк чакта шаян телле,
Елмайта, көлдерә ул.
Шифалы, җылы нурларын
Безләргә иңдерә ул.
Бу күңелдә – кичке шәфәкъ,
Айлы төннәр, таң нуры.
Бу күңел – бетмәс-төкәнмәс
Сихри сүзләр сандыгы.
Бу күңелдә милләтемнең
Бар шатлыгы, бар моңы.
Нинди бәхет шигърияттә
Җанга дәва барлыгы.

### *Бер әртилдә*

Бу вакытта күпләр йоклый,
Бездә инде ыгы-зыгы.
Бу әртилдә хәлләр шундый.
Һай эшләрнең тыгызлыгы!
Сабырлыкка ниләр җитә?
Сабырлык бит – җанга терәк.
Тормыш белән буталганбыз –
Анысы кирәк, монысы кирәк.
Алда тора мөһим эшләр,
Вак-төяге читтә кала.
Безнең ише юләрләргә
Вак-төяк тә җитә кала.
Таң туганчы дау кубардык
Булып узган хаталардан.
Элеп алдык, селкеп салдык
Бер-беребезнең якалардан.
Безнең инде тамак беткән,
Кешеләрне әрли-әрли.
Кояш әле черем итә
Түшәгендә әлли-бәлли.
Таңнар туа, кичләр җитә,
Эшлисе эш һаман кала.
Йөрәгенә каннар саугач,
Күпме яшәр чамаң кала!

### ***Хакыйкать***

Бу тормышта булырмы бер урталык,
Бетте дөнья ялган белән буталып.
Хакыйкатьнең калмады бер бөртеге,
Калды фәкать бюрократлар төркеме.
Күпме куштан хаким булып калдылар,
Буш вәгъдәләр белән безне алдыйлар.
Бу хакимнәр хакыйкатьтән еракта,
Гакыллыны саный алар дуракка.
Булмыйдыр шыксыз көзләрдән яз көтеп,
Таш бәгырьле бәндәләрдән наз көтеп.
Бу тормышлар салынырмы җайга соң?
Кайда соң асыл хакыйкать, кайда соң?

### ***Яшьтәшләр***

Яшьтәшләр еракка киттеләр,
Гомерләр сагышлы үттеләр.
Сагынып-юксынып аларны
Минем дә чәчләрем агарды.
Яшьтәшләр яшиләр читләрдә,
Язмышлар чит җиргә юлыккан.
Тик алар белмиләр безнеңчә,
Нигәдер телләрен оныткан.
Айларга, елларга тиңдер ул
Еракта үткәргән минутлар.
Өммәтен, милләтен белмичә
Тәгәрәп үсәләр оныклар.
Берәүләр киттеләр солдатка,
Туган ил сагында торырга.
Телләрен калдырып кайттылар,

Йа Хода! Ни генә кылырга?
Аерылып, өч еллар буена
Чәчләрен ят җилләр тарады.
Чит телгә табыну – бер гомер,
Саташып яшәргә ярады.
Милләттәш, тайпылма юлыңнан!
Язмышлар кыйблага борылган.
Горурлан, милләтең мактаулы,
Саф татар булуыңнан горурлан!

### *Хәлләремне сорамагыз*

Хәлләремне сорамагыз,
Барыбер бит алдалыйм.
Әллә әйбәт, әллә начар,
Үз-үземне аңламыйм.
Төннәр буе җырлар язам,
Әллә нинди бәндә мин.
Аңламассыз бу мизгелдә,
Сез аңламас хәлдә мин.
Әле җанда сүтелмәгән
Билгесезлек йомгагы.
Йөрәгемне авырттыра
Татлы газап тулгагы.
Хәлләремне сорамагыз,
Минем хәлләр караңгы.
Менә тибәр, менә тибәр
Серле шигъри яралгы.

### *Акча исе*

Акча исе булмый, диләр,
Була шул акча исе.
Акча исенә исереп,
Акылын җуя кеше.
Вөҗданын җуя, намусын,
Хәрәм акчалар кереп.
Туганын, дусларын сата,
Чабата саткан кебек.
Зур-зур түрәләр эләгә
Акча әсирлегенә.
Уйласаң, исләрең китәр
Кеше исәрлегенә.
Кешегә күпме кирәк соң
Бер гомер яшәр өчен?
Бары бер генә гомер бит,
Артыгын яшәмисең.
Кайберәүләр кәләш сайлый,
Мөлкәтен-малын күреп.
«Бай хатынга тап булдым», – дип
Сөйләп йөриләр көлеп.
Кешеләр дә авырып китә,
Вакытлы сырхау була.
Тик рухи яктан сырхаулар

Йөрәкне сыкрандыра.

### *Язлар килә*

Кыш апрельне ачулана,
Тик файда юк һичбер төрле.
Карлар эри басуларда,
Табадагы май шикелле.
Җылы нурлар җиргә иңде,
Кардан әрчи тау битләрен.
Җылы яктан кошлар килде,
Сизеп бездә яз җиткәнен.
Кызыл комач офык яна,
Кызыл шәүлә болытларда.
Торна иптәш, килеп җиткәч,
Тәпи бирде оныкларга.
Язлар килә, язлар килә,
Тәрәзәне кага өмет.
Иркәләнә басу-кырлар,
Бишектәге бала кебек.
Дәрьяларда су тавышы,
Боз таулары йөзеп бара.
Шаулап аккан сулар кебек,
Яшь гомерләр узып бара.
Ага сулар, ага гомер,
Язлар әле тагын килер.
Тормыш бөтен, тормыш уңай,
Тыныч көннәр бирсен Ходай.

### *Кырлай юлында*

Әйтерсең таксида түгел,
Пар атта барам кебек.
Кырлайда үз гомеремдә дә
Булмаган идем элек.
Бу якларда йөрмәсәм дә,
Өзмәсәм дә чәчәген.
Һәр түмгәген изге итеп,
Җанда тоеп яшәдем.
Килгән иде бу юллардан
Пар атта җилдерәсем.
Кыска тот, шофер, кыска тот
Чакрымнар дилбегәсен!
Әкияти Кырлай төбәге,
Як-ягы үзән генә.
Таксида җилдерәм гүя,
Кулларым өзәңгедә.

### *Тормыш дулкыннары*

Тормыш дулкыннары үзе белән
Алып китте мине ерак юлга.
Мин диңгездә колач җәям хәзер,
Сау бул инде, сау бул, тыныч елга.
Ташкын кичү җиңел нәрсә димә!

Әй чайкала дулкын бәргән көйгә,
Әй чайкала мин утырган көймә.
Ярлар ерак инде, ярлар ерак,
Мин агымның йөзәм уртасыннан.
Тормыш мине, юри сынар өчен,
Уңга-сулга бәреп йөртә сыман.
Ярсу сулар ага, мин дә агам,
Бәргәләнеп кыя, ташлар аша.
Мин ризамын кырыс язмышымнан,
Чит ярларга илтеп ташламаса.

### *Акбүз атым*

Акбүз атым, зинһар, өзгәләнмә,
Сабыр гына атлап, акрын бар!
Без узасы юллар чикләнмәгән,
Алда әле бик күп чакрымнар.
Бабаңнарны яхшы хәтерлим мин,
Хәтәр иде безнең татулык.
Сугыш елларының газапларын
Алар белән бергә татыдык.
Авыр иде, авыр ул чакларда,
Сездә булды бөтен таяныч.
Кадерегез бетеп бара никтер,
Шунысы менә бигрәк аяныч.
Сез кешегә юлдаш булсагыз да,
Гомерегез уза йөгәндә.
Кешеләрне дә бит йөгәнлиләр,
Юлларыннан язып йөргәндә.
Маңгайга да буй-буй сырлар сызды
Бергә йөргән еллар арасы.
Тик намусны кайчак рәнҗетәләр,
Әрнеп куя йөрәк ярасы.
Кырын ятып уйга чумып барам,
Кар шуыша чана астыннан.
Гомер юлың күпме узылса да,
Калган эшләремне азсынам.
Акбүз атым, артык өзгәләнмә,
Сабыр гына атлап акрын бар!
Максатларга кайчан җитәбез соң,
Артта калды күпме чакрымнар?!

### *Җил җимергән капкалар*

Җилбер-җилбер искән җилләр
Җилкапканы җимергән.
Теләп алган каза түгел,
Җил хәлләрен кем белгән?

Ни кылырсың, һаман артса
Җил җимергән капкалар.
Җил җимергән капкаларны
Кемнәр кайтып каккалар?

Китәләр яшьләр авылдан,
Калалар картлар торып.
Искегә терәк куясың,
Яңаны булмый корып.

Күңелдә бетмәс сагыш бар,
Юксыну сагышыдыр.
Тышта кемдер йөри кебек,
Малайлар тавышыдыр.

Бәла-казалар китереп
Аптыратты җиле дә.
Тышта кемдер йөри дисәм,
Йөри икән җил генә.

## *Сары төсләр*

«Сары төсләр сагыш тели» дигән
Борынгыдан калган ырым бар.
Хак түгелдер, моны борынгылар
Юри генә әйткән булырлар.
Нигә дисәң, офыкларга кадәр
Игеннәр бит тоташ сарыдан.
Шуңа күрә, ахры, гомерем буе
Сарыларга карап табынам.
Кырга чыксам, күзнең явын ала
Табигатьнең күпме буявы.
Сары чәчәкләрне кимсетә күк
Кешеләрнең ырым юравы.
Еракларга киттем, кырларымнан
Юлларыма гөлләр сарылган.
Гөлләремә ничек үпкәлим соң?
Сагышландым фәкать сагынудан.
Яшьлегемдә мәгърур иңнәремә
Сарылып килгән бәхет шикелле,
Сары көзләр сине юлдаш итеп,
Тормышымны бөтен иттерде.

## *Эчтәлек*

**I**

Туган туфрак ............................
Авылым ................................
Гүзәллеккә омтылып ........................
Бу туфракта .............................
Күл буенда йөрим ..........................
Чиратлар ................................
Авылым таңнары ...........................
«Авыл инде картлык кичерә...» ..................
Татар йорты .............................
Гомер узган саен ............................
Күзләргә керәбез ...........................
Соңару .................................
Кызылъярның кызыл яры ......................
Барҗы Умга якларында ......................
Ата йорты ...............................
Дөнья гаме ...............................
Нигез ..................................
Тәрәзәләр ................................
Гөлдем тавы ..............................
Яшьлек хисе ..............................
Барҗы .................................
Йөрәк ярасы .............................
Уртак дуслык .............................
Каз өмәсе ................................

Җиде юл чатында торасың .....................
Сусыз тегермән монологы .....................
Татар дөньясына мулла кирәк ...................
Кырындыда бер көн ..........................
Туган көнем .............................
Гүзәллек дәрьясы ...........................
Шагыйрьләр килгән авылга .....................
Яңа ел ................................
Кунаклар кайта каладан .......................
Агымсуда акчарлаклар... . .......................

**II**

Моң тулы йөрәгем ..........................
Йөрәк ялкыны ............................
Бәхет юллары ............................
Сиңа .................................
Яшьлек ................................
Сөю-сәгадәт .............................
Улымны өйләндерәм .........................
Бәхетле мизгелләр ..........................
Йөгән .................................
Ялгышлар ...............................
Кодагыйлар ..............................
Ишкәкче карт ............................
«Синең белән бергә...» .........................
Адаштым ..............................
Чишмәгә төшкәннәр киленнәр *(Җыр)* .............

**III**

Икеләнү ...............................
Картаямыни соң йөрәк? ......................
Гомер юлы ..............................
Җилләр исә .............................
Карт юкәләр яшь чәчәктә ....................
Еллар чаба ..............................
Эзләр ................................
Без бит әллә нишләдек ......................
Елларым, язмышларым ........................
Яшәү нигезе .............................
«Кара болытлар куерып...» .....................
Елак гомер ..............................
Күккә ашу ..............................
Имзасыз хат .............................
Әҗәт ................................
Якты эзләр ..............................
Бичарага ни чара? ..........................
«Әдип тә син...» ...........................
Яңгыр ява ..............................
Алданулар ..............................
Изге гамәл ..............................
Уйланулар ..............................
Варислар ...............................
Тизләнеш ..............................
Күләгәдә ...............................
Хатирәләр ..............................
Бу мохитта .............................
Мираслар ...............................
Кәмитләр ..............................
Күңел тәрәзәләре ..........................
Иблисләр ...............................
«Ике фикер, ике акыл...» ........................
Меңнән бер киңәш ..........................
Соңгы юл ..............................
Кырыслык ..............................
Иҗтимагый үзәк ...........................
Изге бурыч ..............................
Упкын .................................
Юану .................................
Хыял-аргамагымда ..........................
Безнең тормыш ...........................
Күнегәсең икән ...........................
Урманнардан урап кайтам ....................
Афәт ................................
Былбыл ...............................
Баганалы юллар ...........................
Гомерләр кичәсең дә ........................
«Яшьлек дәрте ташып торган чакта...» ............

Тәкъдир ................................
Гомерләр узып бара ..........................
Утсыз ялкын .............................
Бакча гөлләре ............................
Соңладым ...............................
Үрләр .................................
Эзләнү .................................
Иләк .................................
Елмаюлар ...............................
Азатлык хакына ...........................
«Яңарыш»ка ..............................
Язгы аклык ..............................
Шомлы көннәр ............................
Буталышлар .............................
«Күп ишеттек инде гайбәт сүзне...» ..............
«Акылың кыска...» ..........................
«Күңел елдам...» ............................
«Телең бетте...» ...........................
Шифаханә ятагында .........................
«Китабыңны кулга алдым, дустым...» ..............
Хәтер .................................
Ак хыял ................................
Җырлар яздым ............................
Бер ялгышым ............................
Чарасызлык .............................
Ходай кичererме? ..........................
Тамыр .................................
Дошманнар ..............................
Базарда вөҗдан сатылмый .....................
Зур ышаныч .............................
Мәкер .................................
Төзәлде китек күңел ........................
Дулкыннар җыры ..........................
Замана караклары ..........................
Изгелек кыл .............................
Кешелеккә ..............................
Казанымда апрель азагы ......................
Юлбасарлар ..............................
Мөстәкыйльлек ...........................
Яз, каләмем, яз әле .........................
Тормыш юлларында .........................
Нинди холык .............................
Чит ярдагы якын дустым .....................
Ыштыр ................................
Золым .................................
Давылны юксыну ..........................
Авырып алдым ............................
Язмышлар ..............................
Авыр хәбәр ..............................
Китап сүзе ..............................
Мәҗнүннәр ..............................
Учаклар ................................
Соңгы юл ...............................
Тукай рухы, заман агышы .....................
Төш ..................................
Хакимнәргә ..............................
Таңнарга каршы барамын... ....................
Яңа ел килә, Яңа ел .........................
Тузан бөртеге ............................
Дуска .................................
Сыкрый урман ............................
Бер авыру сүзләреннән .......................
Табигатьнең үз кануны ......................
Озын гомер теләмәгез миңа ...................
Этлекләр ...............................
«Таңга каршы озын юлга чыктым...» ...............
Җәйге иртә .............................
Язмышым үзәннәрдә ........................
Шофер дуска .............................
Шигъри дәва .............................
Бер әртилдә .............................
Хакыйкать ..............................
Яшьтәшләр .............................
Хәлләремне сорамагыз .......................
Акча исе ...............................
Язлар килә ..............................
Кырлай юлында ...........................
Тормыш дулкыннары ........................
Акбүз атым .............................

Җил җимергән капкалар .......................
Сары төсләр .............................

Литературно-художественное издание

***Мусин*** *Чингиз Мулламухаметович*

***Дорога жизни***

Стихи

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Мусин*** *Чыңгыз Мулламөхәммәт улы*

***Тормыш юлы***

Шигырьләр

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Й.М.Вәлиәхмәтов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 30.06.2006. Форматы 70х90 1/32. Офсет кәгазе. «Korinna» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 5,85. Шартлы буяу-оттиск 6,14.
Нәшер-хисап табагы 6,41. Тиражы 1000 д. Заказ З-507.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан,
Бауман урамы, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.